ТУКАЙ БЕРЛӘШТЕРДЕ

Башкалада узган Туган тел көненнән соң уйланулар

> 5

«АЛТЫН» ТУЙ

«ВТ» хәбәрчесе туй уздыруның чыгымнарын санады

> 16



НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА:

«Халык язучы дисә, шуңа канәгать»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 60 (29027) | Җомга | 28 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

ВАКЫТЛЫЧА

ФАТИРНЫ АРЕНДАГА БИРҮ КЕРЕМЛЕМЕ?

Белгечләр илнең кайсы шәһәрләрендә торак сатып алу отышлырак икәнен ачыклаган. Сөенегез: беренче бишлектә Казан да бар. Баксаң, Татарстан башкаласында күчемсез милекне арендага биреп торудан, аңа салым, коммуналь хезмәтләр өчен түләү кебек барлык чыгымнарны алып атканнан соң да, фатир бәясенең 13 проценты күләмендә еллык табыш алып була икән. Без Казанда җиде фатирын тәүлекләп арендага бирүче милекче белән таныштык. Мондый кәсеп белән күпме акча эшләп була?

> 15

Ишетми калмагыз

Казанда контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пунктына һәр көн саен 30–40лап кеше мөрәҗәгать итә. Сайлап алу пункты җитәкчесе урынбасары Рөстәм Сафиуллин әйтүенчә, контрактны кыска вакытка, шулай ук бер ел һәм аннан күбрәк чорга төзергә мөмкин. Бер елдан ким булмаган вакытка контракт төзүчеләргә бер тапкыр 195 мең сум акча түләнелә. Моннан тыш махсус хәрби операциядә катнашкан өчен һәр ай саен кимендә 204 мең сум күләмендә акча бирелә. Шулай ук дошман техникасын сафтан чыгарган өчен премияләр, өстәмә түләүләр һәм ташламалар каралган.
Рөстәм Сафиуллин сүзләренә караганда, контракт буенча хезмәт итүгә иң кулай кандидат – сайлап алу аша узган 18дән 60 яшькә кадәрге ир-атлар. Алар башта хәрби частьларда әзерлек уза, шуннан соң гына хәрби хәрәкәтләр зонасына җибәрелә.

Санитария-экология икеайлыгы башланганнан бирле Татарстан урманнары 94 кубометр күләмендә көнкүреш калдыкларыннан, 38 чүплектән арындырылган. Урман хуҗалыгы министрлыгының матбугат хезмәте хәбәренә караганда, ведомство карамагындагы оешмалар белгечләре авыл-бистәләр тирәсендәге һәм юллар янындагы урманнарны аерым игътибар үзәгендә тота. Исегезгә төшерәбез: икеайлык 1 апрельдә башланды. Өч атна эчендә өмәләргә барлыгы 227490 кеше чыккан.

Быел Татарстанда 823 кеше, талпан кадалу сәбәпле, табибларга мөрәҗәгать иткән. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе хәбәр иткәнчә, узган елның шушы ук чорындагыга караганда бу күрсәткеч 5 тапкыр зуррак (100 мең кешегә 22,04 кеше туры килә). Белгечләр кешеләрнең тәненнән алынган 156 талпанны тикшергән. Шуның 20сендә талпан боррелиозы (йогышлы авыру) табылган. Татарстанның 30 муниципалитетында, шул исәптән Казан һәм Чаллыда вируслы талпаннар еш очрый. «Кара» исемлеккә Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Зәй, Тукай, Лаеш районнары һ.б. эләккән. Әлеге җирлекләрдә кешеләргә кадалган талпаннар арасында 87,8 процентының вируслы булуы ачыкланган.

Татарстанда апрель азагы – май башында җылы һава саклана. Көндез һава температурасы +26 градуска җитәчәк, дип хәбәр итә республика Гидрометеоүзәге. Шимбә – 29 апрельдә явым-төшем көтелми. Көндез һава температурасы +20...+26, төнлә +4...+10 градус тәшкил итәчәк. Якшәмбе – 30 апрельдә аз гына яңгыр булырга мөмкин. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +19...+24 градуска, төнлә +8...+13 градуска кадәр күтәреләчәк.
Гидрометеоүзәкнең башлангыч мәгълүматларына караганда, дүшәмбе һәм якшәмбе – 1–2 майда урыны белән яңгыр ихтималы бар. Көндез һава температурасы +21...+26 градуска кадәр җылыначак.
Синоптиклар әйтүенчә, быел майда айлык уртача температура норма тирәсендә (+13,6 градус) булачак.

Районнарда ни хәлләр?

Чүпрәле

Иске Чүпрәле авылында гомер кичерүче Сания Алимова бер гасырлык юбилей бәйрәмен билгеләп үтә. Сугыштан соң ул биш баласы белән тол калган Зартдин Алимовка кияүгә чыга. Балаларның ул чакта иң олысына – 13, ә иң кечкенәсенә 4 яшь була. Алар – дүрт малай һәм бер кыз. Сания апа белән Зартдин абый тагын өч уртак кыз бала да алып кайталар. Алимовлар сигез баланы да илгә-көнгә лаеклы шәхесләр итеп тәрбияләп үстерәләр, белем бирәләр. Бүген Сания апаның 18 оныгы һәм 15 оныкчыгы бар. Район башлыгы Марат Гафаров юбилярга Россия Президенты Владимир Путин һәм Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның котлауларын да җиткерде, бүләкләр тапшырды.
(«Туган як»)

Теләче

Район көрәшчеләре махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә ярдәм ниятеннән хәйрия концерты уздыра. Келәмдә бил бирмәгән батырлар, сәхнәгә чыгып, иҗади осталыкларын күрсәтәчәк. Әйтик, Ранис Галимуллин һәм бертуган Мараковлар җыр башкара, татар көрәшендә иң күп җиңүгә ирешкән егетләрнең берсе Раил Нургалиев нәфис сүз белән сөендерәчәк. Яшь спортчылар белән бергә сәхнәгә кайчандыр шушы район данын яклаган Татарстанның халык артисты Вил Усманов, яшьлегендә мәйдан тоткан, ә бүген Татарстанда танылган фермерларның берсе Сәгыйть Гыйниятуллин, район башлыгы урынбасары Айрат Фәтхуллин да чыгачак.

Питрәч

Район үзәгендә «Кеше приюты» дип аталган бушлай кайнар ризык тарату пункты ачылды. Хәзер мохтаҗларның көн саен (якшәмбедән тыш) 11дән 14 сәгатькә кадәр бушлай төшке аш алу мөмкинлеге бар. «Бу – Татарстанда 14 нче пункт. Бөтен республика буенча без көн саен 2 мең кешене ашатабыз. Бу проектны хуплаучы хәйриячеләр клубы әгъзалары белән без көненә 10000 кешене ашатуны максат итеп куйдык. Бүгеннән башлап бу урында барлык мохтаҗларны, диненә һәм милләтенә карамастан, барысын да ашатачакбыз», – дип сөйләде проектка ярдәм итүче хәйриячеләр клубы рәисе Ильяс Гыймадов. Ризыкны Җәмигъ мәчетендә әзерлиләр.
(«Алга»)

Минзәлә

Роберт Шәймәрданов исемендәге мәктәп театрлары фестивалендә Татарстанның биш районыннан меңгә якын бала катнашкан. Фестиваль кысасында барлыгы утызлап спектакль күрсәтелгән. Аларны театр хезмәткәрләреннән торган комиссия мәктәпләргә йөреп караган. Алты спектакль сайлап алынып, Минзәлә театры сәхнәсенә Мөслим районының Татар Шураны, Сарман районының Илексаз, Минзәлә районының Тауасты Байлар, Актаныш районының Иске Кормаш, Тукай районының Калмия авыллары мәктәпләре һәм Минзәлә шәһәре гимназиясе укучылары чыкты.
(«Татар-информ»)

КЕЧКЕНӘЛӘРНЕҢ ЗУР ПРОБЛЕМАЛАРЫ

БАЛАЛАР ОМБУДСМЕННАРЫ КАЗАНГА ҖЫЕЛДЫ

Балалар проблемалары турында зурларча сөйләшү. Бу көннәрдә Татарстан башкаласында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең XX бөтенроссия съезды узды. Үсеп килүче буынның борчулары хакында сөйләшергә, «авырткан җир»ләрне барларга Россиянең барлык төбәкләреннән дә делегатлар җыелган иде. Тантаналы ачылыш республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында узды.

Форумның быелгы темасы – медицина ярдәме һәм балалар сәламәтлеге. Әйтик, балалар-яшүсмерләр психиатриясе, хәмер һәм наркотикка бәйле ата-аналарга булышу, репродуктив сәламәтлекне кайгырту һәм башкалар. Моннан тыш, ярдәмнең практик яктан ничек чынга ашырылуын да карадылар: форум кысасында күргәзмә дә оештырылган иде.

Утырышта катнашучыларга ил Президенты Владимир Путинның сәламен Россия балалар омбудсмены Мария Львова-Белова җиткерде һәм республикага рәхмәтен дә әйтте.

Форум темасына әйләнеп кайтсак, балалар сәламәтлегенең никадәр мөһим мәсьәлә булуын Мария Львова-Белова саннар белән дәлилләде. Бер ел эчендә омбудсмен аппаратына балалар сәламәтлеге мәсьәләләре буенча меңгә якын мөрәҗәгать килгән. Күпчелеге дарулар белән тәэмин итү һәм медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, республикада барлыгы 852210 бала яши. Хакимият үсеп килүче буынга аерым игътибар бирә, ди Рәис.

– Балаларны һәм аналарны яклау, шул исәптән балалар һәм сабыйлар үлемен киметү, балаларның сәламәтлеген кайгырту һәм тормыш сыйфатын яхшырту, шулай ук ата-аналарның сәламәтлеген саклау мәсьәләләренә аерым игътибар бирәбез. Хроник авырулары, шул исәптән сирәк авырулары булган балаларны яклау фондын оештыру турында Россия Президенты Владимир Путинның карары мөһим һәм вакытлы булды. Шунысы куанычлы: узган елның декабрендә ил Президенты йөкләмәсе буенча мондый ярдәмне алучыларның яше 18дән 19 яшькә кадәр артты. Россия субъектлары бюджетына мондый пациентларга ярдәм итү бик авыр. Фонд аша ярдәм күрсәтелгәнгә без рәхмәтле, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Әлеге төр ярдәм балаларга гына түгел, өлкәннәргә дә күрсәтелсә, бик яхшы булыр иде.

tatarstan.ru

Казан Кремлендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тантанасы узды. Бүләкләрне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов тапшырды. «Бирегә тыл хезмәтчәннәре һәм хезмәт ветераннары, сәнәгать предприятиеләре, мәдәният, медицина һәм мәгариф оешмалары хезмәткәрләре, төрле һөнәр ияләре, меценатлар бар. Һәрберегез – Ватанга һәм туган республикага хезмәт итүнең лаеклы үрнәге. Сезнең казанышлар Татарстан үсешенә хезмәт итә һәм илебезнең уңышлы килачәгенә зур өлеш кертә. Без сезнең белән горурланабыз! Хезмәтегез һәм эшегезгә һәм һөнәрегезгә тугрылыгыгыз өчен рәхмәт белдерәсем килә, нык сәламәтлек, яңа уңышлар һәм казанышлар телим», – диде ул. Бүләкләнүчеләр арасында тыл хезмәтчәне Рәшидә Тукаева да бар. Авыр сугыш елларында ул олылар белән беррәттән колхозда, аннары лаеклы ялга чыкканчы укытучы булып эшләгән. Рөстәм Миңнеханов Рәшидә ханымга күпьеллык хезмәте һәм Бөек Җиңүгә өлеш керткәне өчен «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медален тапшырды.

Тиеннән сум җыела

Татарстанның 38 районы салым җыюда сыната. Эш нәрсәгә бәйле? Бу сорауга Татарстан Министрлар Кабинетында узган киңәшмәдә җавап бирделәр. Хөкүмәт йортында агымдагы елның беренче чирегендә республиканың тупланма бюджеты үтәлеше һәм бу елга бурычлар турында сөйләштеләр. Аны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үткәрде.

Өч айда республиканың тупланма бюджеты 115,7 миллиард сум акча кергән. Шул исәптән, 98,5 миллиард сум салым һәм салым булмаган керемнәргә туры килә.

– Керемнәр буенча вазгыять катлаулы. Казнага кергән акчаның күпмедер өлеше узган елдан күчкән түләүләр. Шуңа күрә безгә тынычланырга иртәрәк. Керемгә салымга бәйле түләүләр күләме кимеде. Быелның өч аенда әлеге төр кертем 46,2 миллиард сум тәшкил иткән. Моңа иң беренче чиратта узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда доллар бәясе һәм нефть курсы түбән тәгәрәү тәэсир итте. Нефть тармагына бәйле федераль законнардагы үзгәрешләр турында да онытырга ярамый. Керемгә салым күрсәткече алга таба да кимеячәк. Чөнки аны нигездә нефтьчеләр түли иде. Бу нисбәттән башка төр салымнарга игътибарны арттырырга кирәк. Татарстанның 38 муниципаль районында физик затларның керемнә салым буенча түләүләр күләме кимегән. Бу мәсьәләне кичекмәстән тикшерү зарур, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Рәисен борчыган сорауга урында ук җавап бирделәр.

– Агымдагы елның беренче чирегендә тупланма бюджетка физик затларның керемнә салымнан 20 миллиард сум акча керде. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бу – 16 процентка азрак. Моның сәбәпләре билгеле. Иң беренче чиратта, шуны әйтәсем килә – ел башыннан бирле салым чигерүләре буенча без халыкка 3 миллиард сумга диярлек күбрәк акча кайтардык. Эш шунда ки, бу елның беренче чирегендә декларация тапшырганнан соң, салым чигерүен кайтару вакыты кимеде. Узган елның шушы ук чорында ул 60 көн булса, хәзер – 19 көн. Декларация тапшыручыларга игътибарлырак булырга киңәш итәр идем. Март аенда гына да документларын дөрес тутырмаган 13 меңләп кешенең эше яңадан тикшерелде. Мондый очракта салым казнага тиз генә барып җитми. 2023 елның 1 гыйнварыннан ил күләмендә Бердәм салым системасы гамәлгә кертелү дә тоткарлыклар тудырды, әлбәттә, – дип сөйләде Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марат Сафиуллин.

Физик затларның керемнә салым җыю буенча калышучы районнарны финанс министры Радик Гайзатуллин да телгә алды.

– Бу мәсьәләдә артта калган 38 районның 23ендә эш фәкать быел салым чигерүләрен күбрәк кайтаруга гына бәйле. Ягъни әлеге күрсәткеч артмаган булса, районнардагы вазгыять тә тотрыклы булыр иде. Алдагы елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, республикада ел башыннан бирле салым чигерүләре ике тапкырдан да күбрәк күләмдә кайтарылган, – диде министр.

Марат Сафиуллин киңәшмәдә уңай хәбәр дә җиткерде. Аның әйтүенчә, физик затларга 2022 елда алган керемнәренә декларация тапшыру өчен тагын берничә көн вакыт бар әле. «Салым керемнәре буенча Татарстан Идел буе федераль округына керүче төбәкләр арасында алдынгылыкны бирми», – диде ул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профессиональ даими нигездә эшләүче депутатлары саны турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 20 апрелендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профессиональ даими нигездә эшләүче депутатлары саны турында» 2003 елның 22 сентябрендәге 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 9 (I өлеш); 2014, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 79 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме ике депутаты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме өч депутаты» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 27 апрель
№ 34-ТРЗ

ТАПШЫРЫЛМАГАН ХИСАП


pixabay.com

Чит илдән сатып алынган кыйммәтле кәгазьләр, «истән чыккан» җир кишәрлеге, керемнәрне киметеп күрсәтү, ялгыш кына капка төбенә алып кайтып бушатылган бер «КамАЗ» машинасы вак таш... Белгечләр республикада иң еш күзәтелгән ришвәтчелек очраклары дип шуларны атый. Ришвәтчеләрнең эзенә төшәр өчен, аларга хәтта кулларына көрәк тә алырга туры килгән.

Татарстан Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең баш киңәшчесе Салават Рәхимов сүзләренә караганда, узган ел башыннан быелның беренче квартал азагына кадәр республикада ришвәтчелеккә каршы 397 тикшерү уздырылган, 390 түрә җаваплылыкка тартылган. «Узган ел мондый тикшерүләрнең 96 проценты җаваплылыкка тарту белән тәмамлана иде. Быел бу күрсәткеч 98 процентка җитте», – ди ул.

Салават Рәхимов сүзләренә караганда, ел башыннан бирле белгечләр республикада дәүләт һәм муниципаль хезмәттәгеләр арасында 19 тикшерү оештырган. Нәтиҗәдә биш кеше җаваплылыкка тартылган. Өчесе – дәүләт хакимияте органнарында җитәкче вазыйфасын башкара, икесе – авыл җирлеге башлыгы.

Салават Рәхимов беренче өч очракка аерым тукталасы итте. Кырын эштә тотылган җитәкчеләрнең берсе укытучы буларак алган өстәмә табышын яшергән, тормыш иптәшенең керемнәрен дә киметеп күрсәткән. Икенчесе исә керемнәре турындагы белешмәдә узган елны сатып алган җир кишәрлеген күрсәтергә оныткан. Өченчесе исә барысын да уздырган. Хатынының 25 чит илдә, шул исәптән АКШ, Нидерланд һәм Кайман утрауларында урнашкан оешмалардан кыйммәтле кәгазь сатып алуын ачыклаганнар. Түрә үзе: «Мондый кәгазьләр тотарга ярамаганлыгын белмәдем», – дип акланган.

«Без чыгымнарны аерым тикшерәбез. Узган ел шундый 30 тикшерү уздырдык. Аның барысында күпләрнең чыгымнары турында тулы булмаган яки ялган мәгълүмат күрсәтүе ачыкланды. Бу очракта кеше дисциплинар яки башка төр җаваплылыкка тартыла. Алар ышаныч югалту сәбәпле эштән үк куылырга мөмкин», – дип сөйләде Салават Рәхимов.

Андыйларны махсус федераль исемлеккә дә кертәләр. Хәзерге вакытта анда ил күләмендә 3 меңнән артык кеше кертелгән. Шуларның 19ы – Татарстаннан. «Анда эләккәч, дәүләт муниципаль хезмәтенә юл ябыла. Әлеге реестрда алар биш ел исәптә тора», – дип ачыклык кертте Салават Рәхимов.

Ришвәтчеләрнең эзенә төшәр өчен, белгечләргә хәтта кулларына көрәк тә алырга туры килгән. Бу хәл Буа районында булган.

– Дәүләт килешүе нигезендә әлеге районндагы бер авыл җирлеге башлыгы юл эшен күзәтеп торырга тиеш булган. Ул югалып калмаган, оешма җитәкчесенә берочтан үзенең капка төбенә дә асфальт салып бирергә кушкан. Шул рәвешле вак ташны капка төбенә алып кайтып аударганнар. Без тикшерү белән килгәндә урамда кыш иде. Иренмәдек, кулга көрәк, лом тотып, капка төбендәге карны көрәдек, аның астындагы ташны тикшердек, – дип сөйләде ул.

Авыл җирлеге башлыгы исә гаебен өлешчә генә таныган. Ә тикшерү барышында аның биш төрле банктагы исәп-хисап счетларын күрсәтмәве дә ачыкланган.

Салават Рәхимов сүзләренә караганда, шуңа охшаш җинаятьләрнең күбесе Биектау, Кайбыч һәм Чирмешән районнарында теркәлгән. Җитәкче бу урында шундук искәртеп тә куйды: бу – иң күп ришвәтчеләр бирелә яши дигән сүз түгел, ә шушы районнарда ришвәтчелеккә каршы көрәшнең тулы куәткә алып барылу нәтиҗәсе. Белгечләр Татарстан Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе белән Мәдәният министрлыгында узган тикшеренүләр вакытында да керемнәрне күрсәткән документларда күпсанлы кимчелекләр тапкан.

Салават Рәхимов ришвәтчелек белән очрашкан яки мәгълүматы булган кешеләргә идарәгә хәбәр салырга киңәш итте. Һәр мөрәҗәгать, хәтта юллаучының исеме күрсәтелмәгән хәбәрләр дә җентекләп тикшерелә, дип ышандыра ул.

– Бер авыл җирлеге башлыгы уңга-сулга җирләр өләшеп яткан. Безгә шул хакта аноним хәбәр килеп ирешә. Хәтта җир участокларының кадастр номерларына кадәр күрсәтелгән иде. Барысы 10 җир участогы. Ни гаҗәп: тикшерә торгач, хатта язылганнарның дөреслеккә туры килүе ачыкланды. Шуңа күрә ришвәтчелеккә бәйле соравы, хәбәре булган кеше курыкмыйча безгә мөрәҗәгать итә ала, – ди Салават Рәхимов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Язучы сүзе

Һава торышы

Менә, энем, синең игътибар иткәнең бар микән, бозылды бит хәзер һава торышы. Әллә ниндигә әйләнде ул, һич кенә дә аңлап бетерерлек түгел. Элек алай булмый торган иде. Кыш җитә икән, алдан ук белеп торасың – кар, боз, салкын. Җәен – кояш, җылы яңгыр, ягымлы җил. Көннәре нинди булса да, һава торышы ягымлы иде, ул кешегә яшәргә, эшләргә ярдәм иткән шикелле иде. Әйтик, печәнгә төшәр алдыннан атна-ун көн тирәсе яңгыр була да, чапкан вакытта туктап тора. Болар шыбыр тиргә төшеп интекмәсен дигәндәй, кояш та нурларын тыебрак сибә, җиле дә назлап кына исеп тора. Печән кибәргә дә әйбәт, эшләргә дә уңайлы. Җыеп алгач, тагын яңгырлап ала. Чөнки печән белән генә эш бетми, игеннәрне дә үстерергә кирәк. Урак вакытында тагын матур көннәр башлана. Һава торышы элек кешегә ярдәм итәдер кебек иде. Хәзер әллә нишләде ул, бер дә аңлап бетермәле түгел.

Элек җәмгыятьтә дә ниндидер даимилек, мантыйк була торган иде бит. Менә син мәктәптә яхшы укысаң, институтка керәсең, анда үзеңне әйбәт күрсәтсәң, яхшы эш урыны табасың. Эшеңдә уңыш казансаң, зур кеше буласың. Кем баласы гына булсаң да, нинди генә сазлыктан чыксаң да, үсәргә мөмкинлек бар иде. Хәзер алай түгел. Әнә минем оныгымның таныш егете ике институт бетергән, бер юньле эшкә урнаша алмый. Ике институт тәмамлап, бер эш таба алмый йөрү кеше башына сыярлык хәл түгел иде элек.

Илләре дә тыныч иде аның. Хәзер кая карама – сугыш-талаш, кая карама – канәгатьсезлек. Кешенең тамагы тук, өсте бөтен, ә күңеле тыныч түгел. Нидер җитми тегеңә, нәрсә җитмәгәнен үзе дә белми, тик җиткерергә тырыша. Шуннан канәгатьсезлек килеп чыга. Әллә, мәйтәм, җәмгыятьтәге шушы үзгәрешләргә дә һава торышы сәбәпче микән? Һава торышы кебек, бәлки, адәм баласының табигате дә үзгәрә торгандыр.

Аптырап кына әйтәм инде. Өченче көн менә кояш кыздырды. Бакча казырга дип чыккан идем. Кайда анда җир казу кайгысы. Бөтен дөньяны бораулый кояш нуры, һаваны көйдерә, сулышка аркылы ята. Нинди эш эшләү анда, тик кенә басып торсаң да хәлеңне ала. Бераз шулай селкенеп йөрдем дә кереп яттым. Бер хәлем дә калмады. Өйгә кергәч тә җаным тәнемә сыймыйча йөрдем әле. Ни ятып тынгы табалмыйм, ни эшкә тотынырлык рәт юк. Элек бит ул кояш нуры күңелгә үтеп керә дә, бар дөньяңны яктыртып, җылытып җибәрә, үзеңне дә балкыта торган иде. Хәзер әллә нишләгән ул.

Кичә салкын җил булды. Әллә нинди зәхмәтле нәрсә исә шунда, бөтен дөньяны урыныннан кубарып алып, башка җиргә күчереп куярга теләгән кебек кылана. Күршенең салам эскертен безнең бакчага ташлап бетерә язды. Ачык торган капкаишекләрне каерып ыргытты. Нинди эш эшләмәк кирәк андый вакытта?! Коймага тотына-тотына тышка гына чыгып кердем дә ишекне келәләп куйдым. Минем кебек арык гәүдәле адәмне очыртып алып китәргә дә күп сорамас, Алла сакласын. Синең аша үтәли исәргә теләгәндәй кылана бит ул. Янгын-фәлән килеп чыкмасын, дип, мичкә ягарга да куркып утырдык.

Бүген менә болыт томалаган. Ни явып китми үзе, ни таралмый, бөтен сөякләрне, буыннарны сызлатып тик тора. Сызлау гына булса, әллә түзәргә дә тырышыр идең әле, бу бит – күзне томалый торган болыт, күңелне томалый торган. Бөтен якты уйны куып җибәрә, әйбәт теләкләрне, ягымлы хисләрне өркетә. Юньле кешенең газраилы да шушы хәтле котсыз булып килмидер. Бу сине тәмугка алып китәргә дип килгән шикелле. Алай гына да түгел әле, тәмугны өеңә китереп биргән кебек. Чын менә, үзеңне бөтен галәмдә япа-ялгыз калган кебек тоярга мәҗбүр итә. Янда ярый карчык бар әле әйткәләшеп алырга. Ялгыз булсаң, акылдан шашарга да ерак түгел.

Яңгыр яуса да бик рәхәт түгел инде. Салкын булып ява бит ул хәзер. Элек өйрәнчек бала пианинода уйнаган шикелле тәрәзә төбендә тыпы-тыпы көй чыгарып кына утыра торган иде. Хәзер үче бар адәм сыман бәрә тәрәзәгә, ватып кереп, кыйнап чыгарга теләгәндәй кылана. Җиңгәң кайчак пәрдәләрне дә тартып куя. Мин дәшмим инде. Мондый чакта бик батырланып утырып булмый. Кайчагында бар дөньясына пәрдә тартырлык булам үзем дә.

Әллә нишләде бу һава торышы. Кайчагында бер тәүлек эчендә меңнәрчә кыяфәткә кереп ала бит ул. Менә без кайбер сәясәтчеләр турында: «Иртәнге әйткән сүзе кичкә ярамый», – дибез бит инде. Һава торышы да шулай. Кайчагында берничә сәгать эчендә әллә ниләр кылана. Әле әйбәт дигән көннәре дә адәм аңларлык түгел. Көне буе кыздыра, мәсәлән, җәйге челләдә. Кояш баттымы – сөягеңне сындырырлык салкынгә әйләнә. Элек бит бер дә болай булмый торган иде. Бик арып киткән чакларда, җиргә ятып, йоклап та ала торган идек. Өшеми идек. Йокларсың менә хәзер. Кайчагында мичкә ягып, өйне җылытмасаң, юрган астында да калтырата.

Әллә нишләде хәзер һава торышы. Элек әйбәт иде. Мин моны яхшы белеп әйтәм, туксан ел буе күзәттем.

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Рух

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Җырда җырланганча, төшләргә кереп йөдәтмәсә дә, күңелем Кырлай якларына гел атлыгып тора. Мин Кушлавычта да, Кырлайда да Тукай рухы яшәвенә ышанам. Бу якларда күңел халәте дә үзгә, милли рух та яңа көч-куәт ала кебек, моны бөтен барлыгым, һәр күзәнәгем белән тоям. Казан артына кайту минем өчен изге бер миссиягә әйләнде, ул минем өчен хаҗ сәфәре кебек. Быел Кырлайда шигырь бәйрәме үзенчәлекле узды. Әтнә дәүләт театры артистлары шагыйрьнең Җаектан кайтуы турында театрлаштырылган тамаша күрсәттеләр. Тукай рухы Әтнәдә дә яши, монда солдатка каралырга кайта ул. Шагыйрь буларак та, шәхес буларак та Җаек шәһәрендә җитлеккән Тукайны Казан арты гел үзенә ымсындырып торган. Ә бүген бөтен татар Казан артына тартыла.

Тукай безгә яз көне килгән, яз көне киткән. Әнгам Атнабаев әйтмешли, «...27 ел эчендә шул тиклем ерак киткән, без аны һаман да куып җитә алмыйбыз, ул һаман алда, һаман безне өйрәтә, безне укыта...»

Кызык хәл, мин инде ике ярым Тукай яшен яшәгән кеше, хәтта бераз күбрәк тә, әмма аны «энекәш» дип атарга тел бармый.

Беркөнне оныгым Кәрим: «Дәү әти, Тукай өлкәнрәкме, синме?» – дип сорады. Ничек дип җавап бирергә дә белмәдем, аптырагач: «Ул – бөек кеше», – дидем. Кәримнең теленә Тукай исеме иртә керү гаҗәп түгел, мин аңа җай чыккан саен: «Син Тукай нәселеннән, улым», – дип әйтә килдем, Тукайның бөек кеше икәнлеген үземчә аңлатырга тырышам. «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләренең эчтәлеген сөйлим. Кат-кат сөйләтә оныгым аларны миннән. Ә мин үз чиратымда әлеге әкиятләрне аннан сөйләтергә омтылам. Оныгым күңеленә Тукай рухы, милли рух әкренләп булса да сеңә бара. Беркөнне мәктәптәге укытучысы: «Сезнең оныкӊ үзенең Тукай туганы булуы белән горурланып йөри», – диде. Мактанып түгел, нәкъ менә горурланып. Күңелем тулып китте.

Беркөнне: «Дәү әти, озакламый Тукайның туган көне икән бит, нишлибез?» – ди бу. Тукайны бүген дә исән-сау дип белә, ахры, Кәрим. Мин аңа зиратка баруым, Тукай каберенә чәчәкләр куеп кайтуымны әйттем. Уйга калды бу: «Нигә мине дә үзең белән алмадың?» – диде. Аннан соң Тукайның кайда туганлыгын, ничә яшьтә үлгәнен сорашты. Тулыр-тулмас 27 яшьтә үлгәнен әйткәч: «Миннән өч кенә мәртәбә зуррак икән», – дип куйды. Алла боерса, быел май ахырында оныгыма тугыз яшь тула. Мин аны Кушлавычка да, Кырлайга да алып барырмын, бала күңеле аңларлык итеп бөек туганы турында сөйләрмен. Без: «Күңелләрдә Тукай рухы яшәсә, татар да яшәр», – дип әйтергә яратабыз. Бу – дөрес тә. Шул ук вакытта, рухның яшәве, аның күңелләргә ни дәрәҗәдә ныклап кереп урнашуына да бәйле. Сабый күңеле исә – уңдырышлы туфрак кебек, милли хисләрне иртәрәк чәчсәң яхшы.

Татар бар җирдә гомер-гомергә Тукай булган һәм... Тукай рухы булган җирдә – татар. Чит мәмләкәтләрдә йөргәндә моны үзем дә сиздем. Мәсәлән, Кытай татарлары: «Безне дин, Тукай һәм гаилә яшәтә», – диләр. Аларда Тукайның һич югы бер шигырен яттан белмәгән кеше юк, бала-чагадан алып өлкән яшьтәгеләргә хәтле берсеннән-берсе уздырып сөйлиләр. «Туган тел» шигыре аларда инде күптән милли гимн булып җырлана. Үзләре уздырган төрле бәйрәмнәрне, хәтта туган көннәрне дә «Туган тел» белән башлап «Туган тел» белән тәмамлаулары турында да әйткәннәр иде.

«Шәм үз астын яктыртмый», – диюләре бик дөрес ул. Газиз милләтеңне, Тукай телен саклар өчен туган җирләрдән аерылып яшәү кирәк микәнни соң ул?

Үз җиребездә милли хисләр кайчак ни өчен тупаслана, милли рух кими башлый? Бу сорауларга үзегез дә җавап таба алырсыз, шәт. Таба алмасагыз, озак вакытка читкә, еракка китеп яшәп карагыз.

Күрәсең, яраттырыр өчен бәндә баласын нәрсәдәндер мәхрүм итеп карарга кирәктер. Бер кызыклы гыйбрәт белән әйтәсемне әйтеп бетерим әле. Кайсыдыр елны кием-салым алырга Мәскәүгә баргач, урамда Алмаз Хәмзинне очраттым. Әйтерсең лә гомер буе күрешмәгәнбез, аерылышасы килми, сөйләшеп туеп булмый бит, малай. Юкса Алмаз белән биш-алты көн элек кенә Казанда озаклап сөйләшеп утырган идек. Чит җирдә күрешү бөтенләй башка икән ул!

ЧАЙКАЛГАНДА АРБА АУМАСМЫ?

Үткән елның көзендә икътисадый түнтәрелешнең башлану сәбәпләрен аңлату өчен арбага печән өюне мисал итеп язма әзерләгән идем. Язманың төп фикере шул иде: аерым бер тармакны чамасыз инвестицияләү кризиска китерә, ягъни бер якка гына печән өйсәң, арба ава.

Түнтәрелеш болай башлана: чамасыз күп инвестицияләнгән тармакта башта җитештерү бик нык арта, бәяләр котчыккыч үсә. Соңыннан ихтыяҗ кимү сәбәпле, артык җитештерү кризисы барлыкка килә, җитештерелгән сатылмый, сатылмагач, инвесторлар банклардан алган әҗәтләрен түли алмыйлар, банк кризисы барлыкка килә. Глобаль кризисны моңарчы гел төзелеш тармагы тудырды. Барлык илләр дә торак төзелешен стимуллаштыруга һәрвакыт зур игътибар бирәләр, чөнки а) баш өстендә түбә һәркемгә кирәк, ә) торагың никадәр затлы булса, син шулкадәр абруйлы булып күренәсең, бу – имидж мәсьәләсе (адәм балалары һәрвакытта да танышлары-дуслары алдында кәттә булып күренергә тели), б) торакка бәяләр һәрвакытта да диярлек үсә, шуңа күрә ул байлык саклау һәм арттыру коралы буларак хезмәт итә. Соңгы пунктка аерым тукталыйк әле. Соңгы ике елдагы квадрат метрларның бәясе ничек үсүен күзәтсәк, без ышаначакбыз: бернинди банк депозитлары да, облигацияләр дә, хәтта кыйммәтле кәгазьләр дә квадрат метр кадәр табыш китерә алмый. Кешеләр шул сәбәпле, ихтыяҗ булмаганда да, кредит алып, өсте-өстенә фатир сатып ала, йорт төзи. Шәхси йорт төзелеше мәйданнарында йөргәнем, аралашканым бар минем: мәдәният йортлын да зуррак итеп йорт төзүчеләрнең кимендә бер фатиры һәм бер шәхси йорты бар инде. Кредит алып булса да быел йорт төзеп калу киләсе елда төзүгә караганда отышлырак. Бу уен шулай отышлы дәвам итсен өчен, бәяләрнең туктаусыз үсеп торуы кирәк. Бәяләр тотрыкланса яисә хәтта аз гына төшсә дә, ярыш туктатыла. Киләсе елда арзанграк йорт сатып алып булганда, быел нигә процентлы кредитка тораклы булырга ди әле. Сизә торгансыздыр: бәяләрнең үсеп торуында банкирлар мәнфәгате чагыла. Бәя үскәндә: а) кешеләр зур процентка булса да кредит алачак, ә) кредитын түли алмаса, банкка әҗәтен фатирын сатып түләячәк, димәк, ипотека – банкирлар өчен куркынычсыз инструмент ул. Тегеләй дә оттырмыйсың, болай да оттырмыйсың... кебек. Соңгысына кризис булмаганда дип өстәргә кирәк. Бәяләрнең куәтле үсеше кризис тудырмый калмый, чөнки, бердән, ихтыяҗдан күбрәк төзелә, икенчедән, халыкның сатып алу сәләте кими. Алтын бәясенә квадрат метр алу кызыксындырмый башлый бервакыт. Фатир сәүдәсе тормоз бирә. Төзүче компанияләр яңа йортларны сата алмый, кредитоманнар фатирын йолкып алган банклар да кулларында куык тотып кала. Россиядә шундый вазгыять мәйданга чыкты инде. Краснодар өлкәсендә яңа төзелешнең 83 проценты сатылмый, Омск өлкәсендә – 80 проценты. Саннарны хәлнең катлаулыгын аңлату өчен генә китерәм. Килеп туган хәлгә иң беренче булып шәхси йорт төзүчеләр реакция белдерә. Быелның гыйнвар – март айларында Татарстанда шәхси йорт төзү үткән елның шул чоры белән чагыштырганда сизелерлек кимегән. 2022 елның беренче кварталында 656,2 мең квадрат метр шәхси торак төзелсә, быел 494,9 мең генә. Калькулятор дөрес күрсәтсә, үткән елгының 75 проценты кадәр генә. Быелгы күрсәткеч 2021 елгыдан да байтак түбән. Тагын бер нәрсәне ассызыклыйк: алдагы ике елда төзелеш материалларына бәяләр котырып үсте, шуңа карамастан, халык ярышып төзеде. Быел материалларга бәяләр сизелерлек түбәнәйде, шулай да шәхси йорт төзелеше кими. Гомумән алганда, торак төзелеше быел да бик нык үсә ул. Төзелеш компанияләре тормозга баса алмый әлегә. Беренче кварталда үткән елның шул чоры белән чагыштырганда торак төзелеше 131,0 процент тәшкил итә. Әмма... сатылмый торган фатирлар төзелә. Казанда торак бәясенең күрше өлкәләр башкалалары белән чагыштырганда рекордлы булуын да искә алырга кирәк. Чагыштырыгыз: уртача фатир бәясе Казанда – 9,2 миллион сум, Самарада – 6,1 миллион.

Вазгыятьнең куркыныч якларын санап чыгыйк әйдә. Сатылмый икән, төзелеш иртәме-соңмы тукталырга тиеш була. Һич югында кискен темплар белән кимергә. Төзелеш үзе генә туктамый, аңа хезмәт күрсәтүче күпсанлы заводлар туктый. Чылбыр реакциясе килеп чыга. Финанс тармагы да, җитештерү тармагы да кризиска кереп бата, җимерелә. Аңлый торгансыздыр инде: хөкүмәт моңа юл куймаска тырыша. Кризистан котылуның бер генә юлы бар: ихтыяҗны үстерү. Моның өчен хезмәт хакларының шундый итеп артуы кирәк: уртача бәясе 9 миллион сумнан ашып киткән фатир алу куркыныч булып тоелмасын. Хөкүмәт һәрвакытта да тапталган бер юлдан атлый андый чакта: минималь хезмәт хакларын күтәрә. Шундый итеп күтәрә: кичә ярыйсы гына булып тоелган хезмәт хакы бүген минималь булып кала. Бу – популизм, билгеле. Вакытлыча рәхәт булып тоелачак, әмма бәяләрнең яңа үсеше янә тупикка китереп терәячәк. Тәгәрмәчтә чапкан тиен хәле бу. Фатирларның бәясен төшерү ысулы да өметсез. Бәя төшерү тармакның торгынлыгына гына китерәчәк. Бәясе төшкән активка кешеләр кызыкмый башлаячак. Кемнең, чынлап та, ихтыяҗы бар, фатирны шулар гына алачак. Ихтыяҗның мөмкинлек белән туры килүе дә кирәк бит әле монда. Мөмкинлеге булган россиялеләр фатирны Анталиядән һәм Дубайдан ала, монда акча тотмый. Геосаяси вазгыять тә комачаулый, димәк, бездәге торак төзелешенә. Үзебезнең байлар капиталны читкә качырганда, чит ил инвесторлары монда килми дә килми инде.

Төзелешнең башланып килүче кризисы – инвестицияләрне бер тармакка гына юнәлтү нәтиҗәсе ул. Печәнне арбаның бер генә ягына өю шул хәлгә китерә. Тармакның үсеше башка тармакларда авыр хәл тудыра андый вакытта. Гаилә бар бюджетын торак алуга тотса, ашау-эчү, кием-салым һәм башка ихтыяҗларын чикләргә мәҗбүр була бит инде. Рәхим итегез, Россиядә сөт кризисы бара. Белгечләр аны ихтыяҗ кимү сәбәпле дип аңлаталар. Гафу итегез, кеше сөт продуктларын куллануны киметә икән, димәк, ул ач яши. Эченә кереп карасаң, ул тармакта барысы да башкачарак һәм катлаулырак икәнен күрә аласың. Төпле анализ ясасаң, сөт кайгысының очы бик зур проблемаларга килеп тоташуын күрәсең. Алар нигездә финанслау кытлыгына килеп тоташа.

Төзелеш тармагына яңадан әйләнеп кайтыйк әле. Җитештерү арткан саен бәянең артуы, хәтта ихтыяҗ кимегәндә дә, бәя һәм җитештерү үсү балансның бик нык бозылуын аңлата. Тармак ясалма рәвештә үстерелә дигән сүз бу, куык кабартыла. Куыкны тишеп, гадәти базар көйләвенә кайтырга булыр иде. Бу – шок дигән сүз. 1992 елны хәтерлик әле. Безне ул чакта шок терапиясе белән дәваламак булдылар. Шогы булды, терапиясе булмады аның ләкин. Андый шокны Хөкүмәт үзенә рөхсәт итә алмый бүген. Шок рөхсәт сорап тормыйча да килеп керә ала. Аннан качу һәм котылу өчен, тармакны яңадан өстенлекле финансларга, гиперинфляция спирален бөтерергә туры киләчәк. Монысының да мөмкинлекләре чикләнгән хәзер. АКШта банк түнтәрелешен шул ысул белән дәвалап яталар, нәтиҗәсе кыска вакытлы. Сишәмбе сәүдәсендә Америкада First Republic Bank – ФРС рейтингында зурлыгы ягыннан 14 нче урында торган кредит оешмасы үзенең кырык процент кыйммәтен югалтты. Түнтәрелеш алдагы көннәрдә дә барган иде. Дөрес булса, First Republic Bank 90 процентка очсызланды инде, диләр. Америкаәннар ашыгыч рәвештә банк депозитларындагы акчасын коткара. Банк инде банкротлык хәлендә. Ул ипотека кредитлары белән шөгыльләнгән. Хөкүмәтнең акча басу хисабына бөлгән банкларның активларын сатып алуы да, янган депозитларны халыкка тулысынча кайтарырга биргән вәгъдәләр дә – берсе дә коткармый. First Republic Bank март аенда ук банкротлык хәлендә иде, ФРС аны акча яңгыры астында тотып яшәтмәкче булып карады, барып чыкмый. Көнбатыш банкларның чылбыр реакциясе белән җимерелүләре бар дөньяга таралачак ул. Бу – вакыт эше. Акчасын кая куярга белмәгән нефть державалары да бервакыт бөлгенлек хәлендә калачак, чөнки, бердән, чималга бәя төшәчәк, икенчедән, май катламы урынына туплаган акчалары Көнбатыш банкларында саклана. Хәтта ки күп илләрнең алтын запасы да АКШ ФРСы һәм Лондон банкында саклана. Без глобаль финанслар дигән бөек йөкнең чайкалуын күрәбез, чөнки арбага дөрес өелмәгән. Алар чайкалганда, бер почмагына торак төзелеше дигән йөк чамасыз өелгән Россия арбасы нишләр? Мине шул күбрәк кызыксындыра.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ТУКАЙ ЫШЫГЫНДА

ТУГАН ТЕЛ КӨНЕННӘН СОҢ УЙЛАНУЛАР

Илдар Мөхәммәтҗанов

Тукай сүзе кайтты Казанга! 26 апрель – татарның бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көнендә Татарстан башкаласы «милли хисләр белән ялкынланды».

Нәрсә җитми? Нәрсә кирәк?

Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында яуган 26 апрель иртәсен татар җәмәгатьчелеге, һәрвакыттагыча, Габдулла Тукай һәйкәле янында каршы алды. Шагыйрь янына республиканың беренче затлары – Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев килгән иде.

Шуннан соң Рөстәм Миңнеханов, 2023 елның Укытучы һәм остаз елы булуын исәпкә алып, галим-галимәләр, мөгаллим-мөгаллимәләр, кыскасы, татар зыялылары белән очрашты. Әдәбият, тарих, фән һәм белем бирү өлкәсендәге кайбер мәсьәләләр турында фикер алышу булды ул. Тагын да төгәлләп әйтсәк, очрашуда сүз алган зыялылар тәкъдим-теләкләрен җиткерде, Рөстәм Миңнеханов исә, аларның барысын да хуплап, киләчәктә чынга ашырыр өчен нинди ярдәм кирәклеген сорады. Кайберләренә аерым тукталыйк.

Әйтик, Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институтының фәнни хезмәткәре Динә Гатина-Шәфыйкова Татарстан һәм Россиянең төрле музейларында саклаучы **татар милли киемнәре** һәм алар турындагы мәгълүматны туплап, системага салып, зур бер басма әзерләргә тәкъдим итте. Соңгы арада еш телгә алына торган проблема бу. Аның гамәли чишелешен Рөстәм Миңнеханов үзе тәкъдим итте.

– Музейларга экспедицияләр уздырырга, костюмнарны реставрацияләр өчен урын булдырырга кирәк. Барын да туплагач, зур гына, матур гына күргәзмә ясарга кирәк. Мин бу тәкъдимне хуплыйм, әмма аны башлап йөрүче бармы соң? Фәннәр академиясе, Мәдәният министрлыгы бергә алып барырга тиештер бу эшне. Шәйхразыевка да (Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе. – **Авт.**) әйтергә кирәк. Бик әһәмиятле эш бу, – диде ул.

Милли кием музейларда гына түгел, көндәлек тормышта да үз урынын тапса, шәп буласы да бит. Татарстан Рәисе дә әйтте бу хакта. «Сабан туйларына милли киемнәр киеп чыксак, гел икенче булыр иде. Безгә кирәк булмаса, кемгә кирәк инде ул тагын?» – диде ул.

Татарстанның халык укытучысы Камәрия Хәмидуллина **татар теле һәм әдәбияты укытучыларын берләштерә торган ассоциация** булдырырга тәкъдим итте. Аның сүзләре белән әйтсәк, бу берләшмә Татарстанда гына түгел, башка төбәкләрдә белем бирүче укытучыларга терәк булыр иде. Фәннәр академиясенең вице-президенты Дания Заһидуллина әйтүенчә, анда югары белем бирү йортларындагы татар теле укытучыларын да кертергә кирәк.

– Ассоциация булдыруның авырлыгы юктыр, аның эчтәлеген уйлап бетерергә кирәк. Башка өлкәләрдәге татар теле укытучыларыбызны барларга кирәк, чыннан да. Һәркайсы белән аерым эшли алмасак, күп нәрсәне югалтачакбыз. Үзебездә дә проблемалар җитәрлек. Уйлашып бетерегез, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Очрашуда күтәрелгән тагын бер проблема **урам атамаларына** бәйле. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни хезмәткәре Ләйлә Дәүләтшина Казанның теге яисә бу шәхес исеме кушылган урам атамалары янына QR-код рәвешендә аңлатма бирергә кирәклеген әйтте. Ахыр чиктә, Казан урамнарының атамаларын тагын бер карап чыгарга кирәк, дигән нәтиҗәгә килделәр. Шәһәргә кагылышы булмаган, тарихта бик үк яхшы эз калдырмаган шәхесләрнең исеме урам кадәр урамга бирелергә тиешме? Ә Татарстан һәм татар халкы өчен зур эшләр кылган шәхесләргә ике-өч йортлык урам гына җитәме? Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, әкрен генә, ипләп кенә әнә шул сорауларга җавап эзләргә кирәк.

– Гел әйбәт кешене генә дә куеп булмый, бераз начаррак кешеләр дә булсын, – дип көлдерде ахырдан Рөстәм Миңнеханов. Һәм бу эшне яхшылап уйлап башкарырга кушты.

Фикер алышуны «Безгә ешрак очрашырга кирәк» сүзләре белән йомгакладылар. Татарстан Рәисе әйтмешли, булдыра алмаслык эшләр яңгырамады, теләк кенә булсын.

Берләш(тер)ү

Очрашудан соң сибәләп торган яңгыр астында Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрына юл алдык. Елдагыча, «милли хисләр белән ялкынланып» узган зур тантанада Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең яңа лауреатларын котладылар. Аларның исемнәрен атаганчы, тамаша турында бер-ике кәлимә сүз. Тамашачы залдан елап чыкты, «Туган тел»не җырлаганда да күпләрнең күзләре чыланган иде. Тукай, дөресрәге, биелгы Тукай образы уйланырга һәм бераз булса да оялырга мәҗбүр итте.

Быелгы тантаналы концерт һәм Тукай премиясе лауреатлары турындагы сөйләшүләр әле шактый дәвам итәр кебек. Инде үзләренә күчик. Шулай итеп, 1 млн сум күләмендәге Дәүләт бүләгенә өч кеше лаек дип табылган. Алар – Себердән татар шагыйре Шәүкәт Гаделша; сынлы сәнгать өлкәсендә милли темага багышланган декоратив паннолар өчен Наилә Кумысникова; архитектура өлкәсендә Түбән Кама шәһәренең милли архитектура әсәрләре өчен Фирдәвес Ханов.

Төмән өлкәсеннән үк килгән Шәүкәт Гаделша премиягә ия булуына тантана тәмамлангач та ышанып бетмәгән иде әле.

– Себер татарларын аерым халык дип чыгарганнар икән. Ишеткәннәремә ышанмадым башта... – диде ул. Өлкән яшьтәге шагыйрьнең күзләрендә яшь иде. – Без бит – бер милләт, бердәм халык. Мине әлеге премиягә тәкъдим иткән Төмән өлкәсе татарларына рәхмәт!

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла фикеренчә, Тукай премиясен Шәүкәт Гаделшага бирү – бердәмлегебезне раслау ул.

– Шәүкәт Гаделша – Себердә туып-үскән шагыйрь. Аның шигърияте шактый үзенчәлекле. Әлеге премияне нәкъ менә аңа бирүнең тагын бер максаты һәм омтылышы – Себер татарлары белән бергә һәм бердәм булуыбызны, әдәби телебезнең уртак булуын исбат итү. Безне аерып карарга ярамый: телебез дә, менталитетыбыз да уртак, – диде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Сәяси факторның башка критерийлардан өстен булып чыгуы әлеге бүләкнең дәрәҗәсенә йогынты ясамый калмас кебек. Хәер, соңгы елларда киң җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнгән премия тирәсендәге бәхәсләр табигый хәлгә әйләнеп бара... Ничек кенә булса да, Шәүкәт агага әлеге премиянең файдасын күреп, иҗат итәр өчен ныклы сәламәтлек телик!

Икенче лауреат – Наилә Кумысникова турында бер кызыклы факт: моннан төгәл 65 ел элек әлеге бүләккә аның әнисе – Камал театры артисты Асия Хәйруллина лаек булган.

– Шуңа да әлеге премиягә ия булу – минем өчен икеләтә бәхет. Күн сәнгатенә – безнең бай һәм кабатланмас мирасыбызга мондый игътибар һәм ихтирам күрсәткәннәргә өчен зур рәхмәт! – диде безгә Наилә ханым.

Тукай премиясе тапшырылгач, күпләр өчен көтелмәгән тагын бер вакыйга булды: ике кешегә «Татарстанның халык шагыйре» исеме бирелү турында хәбәр иттеләр. Әлеге дәрәҗәле исемгә Флера Гыйззәтуллина һәм Наил Касыймов лаек булды. Исегезгә төшерәбез: әлеге шәхесләр Тукай премиясенә дәгъва кыла иде. Аларны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов бүләкләде.

Кайда сез, милләттәшләр?

Опера һәм балет театрындагы тантаналы чарадан соң тамашачыларның берише Габдулла Тукай һәйкәле янына ашыкты. Яңгыр әллә кайчан туктап, ялтырап кояш чыкса да, татарның сөекле улына багышланган шигърият бәйрәменә карарга килүчеләр әллә ни күп түгел иде. Һәйкәл янында, гадәттәгечә, олпатлар һәм яшь иҗатчылар шигырьләрен укыды, җырлар җырланды, янә бер кат Тукай премиясе лауреатларының исемнәре аталды.

Нинди яшьтә булуларына карамастан, һәр татар язучысы һәм шагыйре өчен кадерле чара инде бу. Барыбыз өчен дә шулай булырга тиештер ләбаса ул. Кызганыч, Тукайны елга бер генә искә төшермәсәк иде, дисәк тә, соңгы арада елга бер була торган чарага килергә дә кеше ашкынып тормый.

– Яшь чакта Тукай һәйкәле янына баруны зур бәйрәм кебек көтеп ала идек без. Хәзер ул ничектер авыр йөккә әйләнеп бара кебек. Без – куалап өйрәтелгән халык. Укучыларны китерергә, студентларны да лекцияләрдән азат итәргә була иде. Шулай иялләшерләр иде. Тукай шәхесенең онытыла баруына да бәйле түгел микән бу, дип борчылам. Читтә яшәүче татарлар Тукайның шигырьләрен яттан белә. Безнең укучылар, студентлар беләме икән? Бер мәзәк ишеттем. Тукайның туган көнен үткәрдек, үзе генә килмәде, ди, имеш, бер бала. Шул хәлгә калмасак ярый инде... – ди бу җәһәттән хезмәттәшебез Риман абый Гыйлемханов.

Ике дистә елдан артык шигърият бәйрәмен калдырмаучы Ләйсән Шаһиәхмәтова да куәтләде бу сүзләрне. Студент чактан ук канга сеңгән бәйрәм, дип атады ул аны.

– Укуымны 2002 елда ук тәмамласам да, ел саен килергә тырышам. Кызым Алиягә 12 яшь тулды. Аны да кечкенә чагыннан ук калдырмыйм, алып киләм. «Туган тел»не күз яшьләрсез җырлый алмыйм, монда килгәч, горурлык хисе кичерәм мин. Хәер, бер мин генә түгелдер, дип ышанасы килә. Минем өчен шигърият бәйрәме – татар халкының исән булуын күрсәтә торган чара ул, – дип сөйләде Ләйсән ханым.

Казанда Туган тел көне «Мин татарча сөйләшәм» акциясе белән тәмамланды. Оештыручылар, киңрәк аудитория колачлау максатыннан, әлеге чараны «тарихи» урыныннан күчерсә дә, Камал театры каршысында да кеше бик күп күренмәде. Әллә яңгыр, әллә башкасы комачаулады шунда...

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЫ

2023 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы комиссиянең 2023 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген тапшыру турындагы тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Кумысникова Наилә Халит кызына – милли темага багышланган һәм күн мозаикасы техникасында башкарылган декоратив паннолар сериясе өчен;

2) Сибгатуллин Шәүкәт Гаделша улына (Шәүкәт Гаделшага) – «Ачы җыры», «Чоңгыл», «Иман капка ачканда», «Себерем – үз җирем» шигырь җыентыклары өчен;

3) Ханов Фирдәвес Гайнетҗан улына – архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә ватан һәм татар милли мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. МИҢНЕХАНОВ
Казан, Кремль. 2023 ел, 25 апрель, № 255

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык иҗади эшчәнлекләре өчен шагыйрьләр, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» (Иҗат берлеге) иҗтимагый оешмасы әгъзалары: **Гыйззәтуллина** Флера Сабирҗан кызына, **Касыймов** Наил Васыйл улына (Наил Касыймга) **«Татарстан Республикасының Халык шагыйре»** дигән мактаулы исем бирелде.



ИСКИТМӘЛЕ ИКШЕРМӘ

Саба

Соңгы вакытта, кызганыч, авыллардагы проблемалар, аның ятим бала төсле моңаеп-моңсуланып калуы турында күп язарга туры килә. Шуңа күрә бар яктан төзек, матур, гөрләп яшәп ятучы авылларны барып күргәч, күңел аеруча сөенә.

Саба районының Иске Икшермә авыл җирлегенә өч авыл керә: Татар Икшермәсе, Иске Икшермә һәм Өч Нарат. Барысында бергә 394 хуҗалык исәпләнә, аларда 794 кеше яши. Шуның 400гә якыны – Иске Икшермәдә. Әлеге авыл исә социаль объектлары күп булуы белән үзенчәлекле. Республиканың берничә авылында һәм район үзәгендә генә кадет мәктәбе бар. Аның берсе нәкъ менә Икшермә авылында урнашкан. Моннан тыш, авылның балалар бакчасы, фермасы, клубы, китапханәсе, берничә авыл халкының сәламәтлеген кайгыртып торучы амбулаториясе, республика балалар приюты, һәйкәлләре, азык-төлек һәм төзелеш материаллары сатучы кибетләре, мәчете, һәр сабалы яратып ашый торган ипи пешерү, колбаса әзерләү цехлары, чишмәләре, күлләре бар. Шуңа күрә авыл халкының купчелеге эшне читкә китмичә генә үз авылларында таба. Авыл өчен анысы тагын да куанычлы. Авылда татарлар, руслар һәм чуашлар яши.

Алтын урталык

Авылның хуҗалыгы юк, тик бик булдыклы, тырыш, чын хезмәт кешесе булган фермер Зөфәр абыйлары Мөхәммәтшин бар. Хәер, аның биләмәләрен фермер хуҗалыгы кысаларына гына сыйдырып була торган түгел. Рәт-рәт тезелеп киткән заманча корылмаларда 1900 мөгезле эре терлек тәрбияләнә, шуларның 800е – сыерлар. 2594 гектар сөрүлек җирләре бар. Беренчеләрдән булып фермаларын роботлаштырган тынгысыз җан буларак та билгеле әле ул Зөфәр абый.

– Мине 1990 елда Икшермә совхозына директор итеп сайлап куйганнар иде. Бик авыр вакытка туры килде ул. Шулай да бирешмәдек, 1996 елга кадәр яхшы эшләдек. Шуннан соң торгынлык сизелә башлады. Һәм 1997 елда фермер хуҗалыклары итеп оештырырга килештек.

Шулай итеп, бар булган мал-мөлкәтне җиде кеше арасында бүлешергә килешәләр. Тик ул чактагы район башлыгы Фәрит Гыйльмиев ассоциация итеп оештырып, араларыннан бер кешене җитәкче итеп сайларга тәкъдим итә. Ул кеше Зөфәр абый була.

– Вазыйфасы булса да, дәрәҗәсе юк иде аның. Малмөлкәт бүлешкәндә дә нәрсә кала, шуны алдым. Өлешемә тигән бәхетем 40 бозаудан, ярым җимерек хәлдәге берничә фермадан һәм берничә иске техникадан гыйбарәт булды. Кайсыларын шобага салып бүлгән идек. Анда яңарак «КамАЗ» туры килгән иде. Тик анысын да башка кешегә бирдем, – дип искә алды ул вакытларны Зөфәр абый.

Алай булса да, югалып кала торганнардан түгел ул. Кайда нинди яңалык күрә, шуны үз хуҗалыгында сыный. Шулай итеп, фермалар яңара, уңыш арта, аның белән бергә табыш та күбәя.

– Мул уңыш акча китермәскә дә мөмкин, – дигән фикердә тора данлыклы фермер. – Бүген бер сыердан тәүлегенә 35 литр сөт савып алып та бөлгенлеккә чыгарга мөмкин. Бар хикмәт – чыгымда. Мул уңыш артыннан куып, чыгымны арттыру отышлы түгел. Авыл хуҗалыгында алтын урталыкны табарга кирәк. Мин 33 ел шушы принцип буенча эшлим. Эшләгән эш файда китерергә тиеш. Ә аның өчен исәпләү, анализлау, нәтиҗә ясау мөһим. Бүген безнең сөтне 27 сумга алалар. Районда сөтнең уртача үзкыйммәте – 25 сум 75 тиен. Ә безнең хуҗалыкта ул – 21 сум. Бәяләр төшү аркасында, без мартта 6 млн сум акча югалттык. Игенчелек белән генә ерак китеп булмый. Аның янында терлекчелек тә булу кирәк. Акча нәкъ менә терлекчелектә.

Зөфәр абыйның эшендә алып барган икенче төп принцип – барың да бергә эшләү.

– Бездә түрәлек дигән нәрсә юк. Идарә дә итәбез, кул белән дә эшлибез. Хәзер инде үзем физик эшне бик үк алып бара алмыйм, уң кулым – улым иртәдән кичкә кадәр эшчеләр белән бергә. Басуда башкалар таш җыя икән, ул шунда, канау казыйлар икән, иң элек үзе барып тотына, – ди ул.

Эшләре уң булса да, авылның киләчәге дә борчый Зөфәр абыйны.

– Сөтне тапшырабыз гына, чөнки үзебездә һәм күрше-тирәдә фермада эшләргә теләрдәй кеше юк. Бүген минем хуҗалыкта 61 кеше эшли. Авылдашлар да, яшьләр дә бар. Шул ук вакытта үзбәкләрне дә чакырып китерергә туры килде, – ди ул.

> Авылга кешене кайтарыр өчен соңладык инде без. Бу турыда 70 нче елларда уйларга кирәк иде. Ул вакытта авылда шартлар бик начар иде, эре предприятиеләр төзегәч, халык шәһәргә чыгып качты. «Авылда исереклар һәм юләрләр генә кала». Бар җирдә шундый сәясәт алып барылды. Мин үз эшем өчен борчылмыймын. Үземне алыштыра алырдай балалар тәрбияли алдым. Менә авыл кемгә калыр икән?

Кадет мәктәбе

Авылда кадет мәктәбе барлыгына күпләр ышанмый да. Үзебез өчен дә яңалык булды ул. Моңа кадәр әлеге уку йорты турында ишетеп белсәк тә, үз күзләребез белән килеп күргәч, бөтенләй башкача кабул иттек. Биредә укучылар хәрби киемнән йөриләр, казармада яшиләр, һәр бала исәнләшеп уза. Кави Байкиев исемен йөртүче мәгариф учреждениесе 2013 елдан кадетлар мәктәбе статусын алган. Көндезгә сәгать 2гә кадәр балалар гомуми белем бирү программасы буенча белем ала. Шуннан соң 5 нче сыйныфтан башлап укучыларны тәрбиячеләр кабул итеп алып, махсус дисциплина фәннәре укытыла башлый.

– Мәктәпнең төп максаты – илебезгә чын патриотлар тәрбияләү. Шуңа күрә безгә чын ватанпәрвәрләр тәрбияләргә теләгән әти-әниләр килә, – ди директор урынбасары Мәдинә Маканова. – Бездә укырга теләүчеләр бик күп, тик барысын да алырга мөмкинлегебез юк. Моннан тыш, таләпләр бик югары. 5 нче класска балалар математика һәм рус теленнән имтихан биреп керә, саулыкларына, физик әзерлекле булуларына да зур игътибар бирәбез. Кадетлар иртәнге 6дан кичке 8 нче яртыга кадәр мәктәптә. Шуннан соң балалар казармага кайта.

Әлеге вакытта мәктәптә 201 укучы белем ала.

– Безгә республиканың ун районыннан һәм Киров өлкәсе, Башкортстан Республикасыннан килеп укыйлар. Алар казармада яши. Бүген шундый 97 балабыз бар. «Тургай» социаль приютыннан 17 укучы килә. Төрле районнардан килгән балалар белән эшләү җиңел түгел, тик укучыларыбыз сынатмый. Безнең мәктәпне тәмамлап киткән балалар арасыннан ФСБ буенча, хәрби вузларда укучылар бар. Бүген 20дән артык укучыбыз махсус операциядә катнаша.

Кадет мәктәбе укучылары спорт ярышларында да алдынгы урыннарны бирми. Мәктәптә 13 түгәрәк эшли. Уку бүлмәләре барлык кирәкле әсбап һәм җиһазлар белән җиһазландырылган. Укучылар авиамодельләштерү, агачтан эшләнмәләр ясау буенча да бик көчле. Болардан тыш, мәктәпне тәмамлаганда укучылар кулларына җиңел машина йөртү, тракторчы-машинист, «КамАЗ» йөртү таныклыгын бушлай алып чыга.

Мәдәни тормыш

Икшермә халкы җырга-моңга да бик һәвәс булып чыкты. Зурларның «Сударушка», балаларның «Веселинки» ансамбльләре эшли. Болар өстенә, алар җәен капка төпләрендә кич утырулар оештыра. Кич утырырга үз авылларына гына түгел, күрше авылларга да баралар.

– Капка төбендә аерым бер рух хөкем сөрә. Клубка чыкмаган, сәхнәгә менмәгән кешеләр дә бик теләп катнаша монда, – ди клуб мөдире Гүзәл Әхмәтҗанова – Сәхнәгә чыгарып булмаган абыйлар гармуннары белән чыга. Төрле уеннар уйнап, җырлап, бик күңелле кич утырабыз. Авылның бик актив апалары, «умыртка баганасы» бар. Ул яктан мин бик бәхетле. Нинди генә тәкъдим белән чыксам да, шундук күтәреп алалар. Костюмнарга үзләре акча табып, тектереп, бик теләп йөриләр. Бик зур рәхмәт аларга! Безнең эштә иң авыры – кешене сәхнәгә чыгару. Һәркайсының холкын, мөмкинлекләрен, кәефен чамалап эшләргә туры килә. Без үзебез генә дә рәхәтләнеп концерт программасын төзеп, теләсә кая чыгып китә алабыз. Рус ансамбле белән конкурслардан кайтып кермибез.

Авылның мәдәни учагы бүген шөкер итәрлек булса да, киләчәге барыбер бераз гына сагайта, дигән фикерен дә әйтте Гүзәл ханым.

– Әлегә клубтагы чараларда урта яшьләрдәге апалар катнаша. Аларны алыштырырдай яшьләр булырмы – әйтә алмыйм. Әлегә аларны җәлеп итеп булмый. Ә менә балалар бик теләп йөри. Шулай булгач, өмет бар әле безнең, – ди ул.

Яшь җитәкче

Авыл җирлеге башлыгының яшь булуын белгәч, гаҗәпләнүебезне яшереп кала алмадык. 27 яшьлек Алмаз Биккинин хатыны Зөһрә белән ике ул тәрбияләп үстерәләр. Авылның киләчәге – балаларда, яшь гаиләләрдә, дип саный Алмаз үзе дә. Тик алар кебекләр авылда каламы соң?

– Авылыбыз гөрләп торса да, аның киләчәге барыбер борчуга сала. Безнең кебек яшьләр бар, ләкин күп түгел, – ди ул. – Югыйсә биредә рәхәтләнеп яшәр өчен барлык мөмкинлекләр бар. Ольларга гына түгел, яшьләргә дә. Икшермә зур, матур, төзек, район үзәге дә якында гына. Кайсы гына авыл үз иганәчеләре белән безнең кебек горурлана ала икән! Алар бездә күп һәм гел ярдәм кулы сузалар. Алар ярдәме белән чишмәләр, күлләр каралды, күл яннары матурланды. Мәчет, клуб, һәйкәлләребез яңа.

Алмаз үзен авылның чын патриоты дип саный. Авыл советындагы турыдан-туры вазыйфаларыннан тыш спорт белән дә кызыксына ул. Шуңа күрә авыл командалары спорт ярышларында да алдынгы урыннарны бирми.

– Мин авылымны бик нык яратам, – дип Алмаз. – Шуңа күрә монда калырга тәкъдим иткәч, хатыным да каршы килмәде. Акрынлап йорт салып чыктык. Нәкъ менә туган авылымда калып, авылдашларыма булдыра алганча ярдәм һәм хезмәт итүемә сөенәм.

Зөһрә САДЫЙКОВА

АКЧА – БЕЗДӘН, ЧЕЛТӘР – СЕЗДӘН

«СЕТЕВАЯ КОМПАНИЯ» БАКЧА ҺӘМ ДАЧАЛАРДАГЫ ТУЗГАН ЭЛЕКТР ЧЕЛТӘРЛӘРЕН ҮЗ КАНАТЫ АСТЫНА АЛЫРГА ӘЗЕР

«Сетевая компания» җәмгыяте бакчачылык ширкәтләрендәге электр челтәрләрен үз балансына кабул итәргә әзер булуын белдерде. Әлеге яңалык бакча йорты хуҗаларына нәрсә бирәчәк? Энергетиклар белән шул хакта сөйләштек.

Искедән – яңага

Казанда яшәүче Шәйдуллиннарның бакчалары Биектаудагы «Заря – 37» ширкәтендә урнашкан. Башка бакчачылар кебек үк, алар да язны түземсезлек белән көтеп ала. Шулай булмый ни, табигатьнең иң рәхәт, яшәргән чагы бит! Бакча эшләрен башлап җибәрү өчен дә көннәр бик матур тора.

– Сезонны ачып җибәрдек инде. Әменә бакчачылар белән җыелышлар гадәттә май бәйрәмендә була. Рәискә дә коммуналь түләү өчен каралган акчаны шушы вакытларда тапшырабыз, – ди Гөлназ Шәйдуллина. – Шәхсән безнең участокта ут белән тәэмин итүдә зур проблемалар юк. Алай да утның көче булмау, ара-тирә сүнеп китү кебек хәлләр булгалый. Электр чыбыкларының күпчелеге искергән, күрәсең. Ә яңарта башласаң, бу чыгымнар әлеге дә баягы бакчачылар җилкәсенә калыр дип куркабыз.

Ә бакчачылык ширкәтләрендә проблемалар чыннан да җитәрлек. Әйтик, электр линияләренең бакча кишәрлекләрендә урнашуы, аларга керү мөмкинлеге булмау, һава линияләре астында җиләк-җимеш агачлары утырту, юлларның тарлыгы – болар барысы да эшләрдә авырлык тудыра. Моннан тыш, дистә еллар дәвамында тәэкләндерелмәгән челтәрләрнең дә шактый тузган булуы борчу уята.

Татарстан бакчачылар берлеге рәисе Владимир Дейнекин бакча йортларын ут белән тәэмин итүдә килеп туган вазгыятьне яхшы аңлый.

– Электр челтәрләре бакчачылык хуҗалыкларында моңа кадәр хуҗасыз һәм начар хәлдә булды. Хәтта кайбер объектларга килеп, нинди дер эшләр башкарыр өчен махсус техника керү җае да юк. Участокта ниндидер авария килеп чыга калса, ремонтны тәҗрибәле белгечләр чакырып эшләтү дә – бакчачылар кесәсеннән. Бакчачылык ширкәтләрендәге электр линияләрен «Сетевая компания»гә тапшыру алга таба аларны карап тоту, тәэкләндерү, яңарту мәсьәләләрен хәл итәргә ярдәм итәчәк дип ышанабыз.

Моннан тыш, республиканың төп бакчачысы әйтүенчә, әлеге үзгәрешләр ширкәтләрдә өстәмә чыгымнарны да киметер иде.

– Бакча ширкәте штатында электрик тотарга туры килмәс иде. Ә бакчачылар электр челтәрләрен карап тоткан өчен акча түләүдән азат ителәчәк. Алар бары тик киловаттлар өчен генә түләр иде, – ди Владимир Дейнекин.

Хуҗалы чыбыклар

Әлеге вакытта Татарстанда 950 бакчачылык ширкәте исәпләнә. Аларның 629ы электр челтәрләре объектларын (ә бу – 0,4 – 6 кВ көчәнештәге һава линияләре, комплектлы трансформатор подстанцияләре) «Сетевая компания»гә тапшырырга ризалык белдергән.

Моңа кадәр норматив-техник таләпләргә туры китерү өчен, «Сетевая компания» баланстагы хуҗалыкларның чикләренә кадәрге өлешен (0,4 – 6 кВ көчәнештәге һава линияләрен, подстанцияләрне) ремонтлый һәм тәэкләндерә иде. 2016 елдан эчке электр челтәрләрен тикшерү билгеле бер график буенча башкарылды. Гадәттә энергетиклар эчке һәм тышкы челтәрләрне оешмага тапшырырга теләгән ширкәт җитәкчеләре мөрәҗәгатеннән соң килә. Нәтиҗәдә бу көнгә 123 ширкәт «Сетевая компания» карамагына күчкән инде.

Соңгы берничә елда Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә бакчачылык ширкәтләре өчен махсус программа эшләде. Аның кысасында бакча ширкәтләрендә тышкы инженер инфраструктура объектларын ремонтлауга бәйле чыгымнарны каплау өчен республика бюджетыннан субсидияләр бирелеп килде. Ә 2017 елдан башлап ширкәт балансында булып, соңыннан «Электр челтәрләре» предприятиесенә күчә торган электр линияләрен, трансформатор подстанцияләрен төзү, тәэкләндерү өчен ел саен 100 млн сум акча бирелде.

– Шул акча хисабына югары вольтлы линияләр тәртипкә китерелде. Моннан соң эчке электр линияләре дә контрольгә алыначак. Димәк, югалтулар бетә дигән сүз. Линияләр дә каралган булачак, акча да янга кала, – диде Владимир Дейнекин.

2022 елның 14 июленнән федераль законга үзгәрешләр кертелде. Аның нигезендә, бакчачылык ширкәтләренә гомуми файдаланудагы мөлкәтне энергетика компанияләре балансына тапшыру хокукы бирелде. Әлеге эшләр аварияләр санын киметеп, бакчачыларны сыйфатлы электр энергиясе белән тәэмин итү максатыннан эшләнелә.

Бакчачылык ширкәтләре алдында да хәзер зур бурычлар тора. Аларга юлларның киңлеген, технологик коридорларны норматив таләпләргә туры китерергә кирәк булачак. Трансформатор подстанциясенең саклык зонасы киңлеге һәр яклап 10 метрны тәшкил итәргә, ә 0,4 кВ көчәнештәге электр линияләре өчен 2 метрдан да ким булмаска тиеш. Бу эшләр бакчачылык ширкәтләрендәге электр челтәре хуҗалыгын тәэкләндерү, алга таба файдалану һәм подстанцияләр, электр линияләренең саклау зоналарын рәсмиләштерү өчен кирәк.

Нәрсә үзгәрә?

Үзгәрешләр бакчачыларга нинди өстенлекләр бирә соң? «Сетевая компания» оешмасының техник директоры Альмир Латыйпов аңлатуынча, электр челтәрләрен «Сетевая компания»гә тапшырудан бакчачылар отачак кына. Беренчедән, бу челтәрләрне тапшырганнан соң, кишәрлекнең һәр хуҗасы ут өчен тариф буенча гына түләячәк. Ә бакчадагы энергетика объектларын карап тоту һәм бурычларны җыелган кешеләрнең утларын өзү өчен профессионаллар җаваплы булачак. Икенчедән, килешү төзелгәч үк, «Сетевая компания» авария-тәэкләндерү эшләре буенча барлык бурычларны үз өстенә ала. Өченчедән, милек хуҗалары капиталь ремонтка бәйле чыгымнардан азат ителә.

– Программаны тормышка ашыру өчен өстәмә ресурслар кирәк булачак. Алар, беренче чиратта, кулланучыларның мәнфәгатьләрен кайгыртуга юнәлдереләчәк. Без моны үз эшчәнлегебездә һәрвакыт беренче урынга куябыз. Аерым алганда, бакчачылык ширкәтләрендә ремонт эшләре үткәрергә туры килгәндә, әлеге чыгымнарга тотылачак акча компаниянең инвестицияләр программасына кертеләчәк. Баланска кабул ителгән объектлар тәэкләндерелә, яңартыла яки үзгәртеп корыла. Бу исә Татарстандагы бакчачылык ширкәтләрен электр белән тәэмин итүнең сыйфатын һәм ышанычын арттырачак, – диде Альмир Латыйпов.

Үзгәрешләрне Питрәч районының «Автомобилист 1» бакчачылык ширкәтендә дә түземсезлек белән көтәләр. Аның рәисе Миләүшә Ахмедова сүзләренчә, алар күптәннән үз электр линияләрен «Сетевая компания»гә тапшырырга теләгән, тик моңа төрле сәбәпләр комачаулап килгән.

– Бакчачылык ширкәтләре бу үзгәрешләрдән ота гына, – диде ул. – Электр чыбыклары да, трансформаторлар да оешма балансында була. Авария килеп чыккан очракта да, белгечләр килешү буенча бер сәгать эчендә килеп җитеп төзәтәчәк. Бу мәшәкатьләр, ниһаять, безнең җилкәдән төшсә, күңелебез тыныч булыр иде. Безнең бакча 1982 елгы. Трансформатор подстанциясе дә искерде. Алыштыру чыгымнарын бакчачылар белән генә күтәрсәк, шактый кыйммәткә төшәчәк. Ә компания балансына күчкән очракта, әлеге эшләр бушлай булачак.

Сер түгел, бакчачылык ширкәтләрендә җаен да, кышын да яшәүчеләр бар. Әлеге үзгәрешләр алар өчен дә кулай. Тик һәр эшнең үз тәртибе булган кебек, бакчачылык ширкәтләрендәге эчке электр челтәрләрен «Сетевая компания» балансына тапшыру өчен дә билгеле бер шартларның үтәлгән булуы кирәк. Беренчедән, бакчачылык ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышында милекне тапшыру турында карар кабул ителгән булырга тиеш. Икенчедән, электр челтәрләре бакча яки бакчачылык территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең гомуми милке булып саналганда, хуҗаларның ризалыгы мәҗбүри.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Киңәш

Бакча йортларында ел әйләнәсендә яшәүчеләр бакчачылык ширкәте идарәсе белән түгел, ә турыдан-туры «Сетевая компания» белән дә килешү төзи ала. Бу эш ничек башкарыла?

1. Технологик тоташтыру вакытында бакча кишәрлегенә киловаттлар бүлеп бирелгән очракта, килешү төзү тәртибе

Килешү төзү өчен гаризаны «Татэнергосбыт» җәмгыятенә тапшырырга кирәк. Гариза белән бергә паспорт күчермәсе, энергия кабул итү җайланмаларына милек хокукын раслаучы яки җир участогына ия булу һәм аннан файдалану хокукын раслаучы документлар; исәп-хисап приборларын (булган очракта) файдалануга кертү турында документлар; энергия кабул итү җайланмаларының технологик тоташуын раслаучы документлар, ягъни технологик тоташтыру турында акт тапшырыла. Соңгысы булмаган очракта, технологик тоташтыру вакытында бакчачылык ширкәте әгъзасы булып торуны раслаучы документ бирелә. Килешү гариза килгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча төзелә.

2. Кишәрлек яңа гына формалашкан һәм ширкәт составында аңа электр куәте бүлеп бирелмәгән очракта

Энергия белән тәэмин итү килешүен төзү өчен технологик тоташтыру үздырырга кирәк. Сезгә моның өчен иң якында урнашкан энергетика оешмасына гариза җибәрергә кирәк. Әгәр дә бакча хуҗасының кишәрлек чикләреннән 300 метрдан да ким ераклыкта берничә оешманың объекты бар икән, гаризаны аларның теләсә кайсына җибәрергә була. Гаризаны «Сетевая компания»нең рәсми сайтындагы шәхси кабинет аша юллый аласыз.

3. Бакча кишәрлеге сатып алучы электр челтәрләре турында тагын нәрсәне белеп торырга тиеш?

Хокук билгеләүче документлар алганнан соң, һәр гариза бирүче килешүләрне үз исеменә рәсмиләштерергә тели. Шуның өчен документларны яңадан рәсмиләштерүне «Сетевая компания»дә үткәргергә кирәк. Мондый документлар алу өчен, сезгә элеккеге хуҗаның мәгълүматларын күрсәтеп, гариза бирергә кирәк булачак. Актлар 7 көн эчендә әзерләнәчәк, хезмәт түләүле. Эшләр тәмамлангач, яңа милекчегә рәсмиләштерелгән технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында акт бирелә. Бу документ нигезендә «Татэнергосбыт»ка мөрәҗәгать итәргә һәм энергия белән тәэмин итү килешүен үз исемегезгә яңадан төзергә мөмкин.

1 май | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АЛМАШ». Телесериал 16+
10.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ӨЧ ЮЛ». Телесериал 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.30 «Мин бәхетле». Ришат Төхвәтуллин 12+
15.45 «Татар сүзе» 6+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
19.00, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Заман көзгесе» 16+
00.00 «Каравай». Народное искусство Лимы Кустабаевой 6+
00.25 «Рыцари вечности» 16+
01.05 «Ком сәгате» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 12+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 Айдар Фәйзрахманов җырларыннан концерт 16+
10.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 00.40 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.00 Т.Миңнуллин. «ЙӨРӘК МАЕМ» 16+
18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
18.20 «Йөрәк җылысы». Филүс Каһиров концерты 16+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
21.25 И.Мәхмүтова. «КҮРӘСЕМ КИЛГӘН ИДЕ» 16+
23.30, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
04.15 «Башваткыч» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ
06.00 Новости
06.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
06.40 «ПОЛОСАТЫЙ РЕЙС» 12+
08.15 «ВЕСНА НА ЗАРЕЧНОЙ УЛИЦЕ» 12+
10.00 Новости с субтитрами
10.15, 12.15 «ЦАРЕВИЧ АЛЕКСЕЙ» 12+
12.00 Новости с субтитрами
12.35 «ЦАРСКАЯ ОХОТА» 16+
14.40 «БЕДНЫЙ, БЕДНЫЙ ПАВЕЛ» 12+
16.40 Юбилейный концерт Филиппа Киркорова в Кремле «Золотые хиты» (S) 12+
19.15 «ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЕТ ПРОФЕССИЮ» 0+
21.00 «Время»
21.35 Премьера. «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». Многосерийный фильм (S) 12+
22.35 «НЕФУТБОЛ» (S) 12+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
04.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1
05.35 Алла Юганова и Андрей Биланов в фильме «ЛЮБОВЬ С ИСПЫТАТЕЛЬНЫМ СРОКОМ» 12+
09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному» Телеигра
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.45 Юрий Никулин, Андрей Миронов, Анатолий Папанов, Нина Гребешкова, Нонна Мордюкова и Светлана Светличная в комедии Леонида Гайдая «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА» 0+
13.45 Премьера. Концерт Владимира Винокура «Юбилей в кругу друзей» 16+
18.00 «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
21.05 Вести. Местное время
21.20 Елена Великанова, Юлия Галкина, Екатерина Копанова, Михаил Пшеничный, Алексей Демидов, Ольга Прокофьева и Артем Осипов в фильме «ВЫ МНЕ ПОДХОДИТЕ» 12+
01.00 Татьяна Яковенко, Дарья Пармененкова, Борис Хвошнянский и Александр Соколовский в фильме «МОИ ДОРОГИЕ» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 «Лучшие из лучших» 12+
06.30 Автоспорт. G-Drive Российская серия кольцевых гонок. Трансляция из Сочи 0+
07.00, 10.00, 18.55, 21.45 Новости
07.05, 16.35, 19.00, 21.50 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 22.40 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
10.55 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. 1/4 финала. «Тюмень» – «Норильский Никель» (Норильск). Прямая трансляция
12.55 Регби. PARI. Чемпионат России. «Химик» (Дзержинск) – «Енисей-СТМ» (Красноярск). Прямая трансляция
14.55 Гандбол. Кубок России. OLIMPBET. Финал четырех. Мужчины. Финал. Прямая трансляция из Москвы
16.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. Финал. Прямая трансляция
19.30 Футбол. Ретро-матч Победы. «Динамо» (Сталинград) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
23.30 «Наши иностранцы» 12+
00.00 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
00.30 Смешанные единоборства. UFC. Петр Ян. Лучшее 16+
01.30 «Игорь Численко. Удар форварда» Документальный фильм 12+
02.30 «Что по спорту? Владикавказ» 12+
02.55 Новости 0+
03.00 Бадминтон. Кубок России. Трансляция из Казани 0+
05.00 Пляжный волейбол. Чемпионат России. Женщины. Финал. Трансляция из Анапы 0+

НТВ
05.25 Сериал «ПЛЯЖ» (S) 16+
07.00 «Тайны любви». «Позднее счастье Бориса Галкина» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20. 10.20 Борис Галкин в остросюжетном фильме «ОТСТАВНИК» (S) 16+
10.30 Остросюжетный фильм «ОТСТАВНИК-2» (S) 16+
12.30 Остросюжетный фильм «ОТСТАВНИК-3» (S) 16+
14.35. 16.20 Остросюжетный фильм «ОТСТАВНИК. ОДИН ЗА ВСЕХ» (S) 16+
17.00 Остросюжетный фильм «ОТСТАВНИК. СПАСТИ ВРАГА» (S) 16+
19.35 Премьера. Остросюжетный фильм «ОТСТАВНИК. ЗАЩИТА ДЕДОВА» (S) 16+
22.30 Премьера. «Авторадио – 30 лет. Классика» (S) 12+
01.05 Даниил Страхов, Татьяна Казючиц и Анатолий Лобоцкий в остросюжетном фильме «РОЗЫГРЫШ» (S) 16+
04.20 «Военно-исторические маршруты» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
07.20 «РОДНЯ» 16+
09.15 «ДАВАЙТЕ ПОЗНАКОМИМСЯ» 16+
11.15 «КОММУНАЛКА» 16+
15.15 «ВВЕРХ ТОРМАШКАМИ» 16+
19.00 «ЗАВТРА Я ТЕБЯ РАЗЛЮБЛЮ» 16+
23.05 «ЗИТА И ГИТА» 12+
01.55 «РОДНЯ» 16+
03.30 «ВЕРЮ. ЛЮБЛЮ. НАДЕЮСЬ» 16+
06.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА
05.20 «СВЕТЛЫЙ ПУТЬ» 12+
07.10, 08.15 «НЕБЕСНЫЙ ТИХОХОД» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15 «ИЛЬЯ МУРОМЕЦ» 6+
11.10 «ЛЮБИТЬ ПО-РУССКИ» 16+
13.15 «Время вперед». Документальный сериал 16+
18.20 «МАКСИМ ПЕРЕПЕЛИЦА» 12+
20.20 «ОВЕЧКА ДОЛЛИ БЫЛА ЗЛАЯ И РАНО УМЕРЛА» 16+
22.55 «ЛЮБИТЬ ПО-РУССКИ-2» 16+
00.50 «ЛЮБИТЬ ПО-РУССКИ». «Губернатор» 16+
02.25 «БОЛЬШАЯ СЕМЬЯ» 12+
04.10 «Кремль. Страницы истории». Документальный фильм 12+

2 май | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АЛМАШ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал 16+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӨЧ ЮЛ». Телесериал 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.30. 21.00 «Соотечественники» 16+
15.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
15.45 «Татар сүзе» 6+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Соотечественники». В плену слухов. Абдулла Баттал 16+
00.50 «Каравай». Истоки. Искусство войлока 6+
01.15 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00 Баянда Максат Гомәров уйный 6+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». Телефильм 16+
15.00 «Сандугач булып сайрармын». Гөлшат Имамиева җырлый 6+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости с субтитрами
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости с субтитрами
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости с субтитрами
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости с субтитрами
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «КУКЛЫ НАСЛЕДНИКА ТУТТИ» 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». Многосерийный фильм (S) 12+
23.00 Премьера. «МАЭСТРО» 12+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
03.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Вести. Местное время
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Вести. Местное время
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
21.05 Вести. Местное время
21.20 Русская серия. Премьера. Мария Порошина, Ярослав Бойко, Сергей Жигунов, Анна Якунина, Максим Аверин и Галина Безрук в телесериале «ВСЕМ ПО 50» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьевым» 12+
02.05 Александра Урсуляк, Даниил Страхов и Валентин Смирнитский в телесериале «ПОИСКИ УЛИК» 12+
03.40 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнев, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев и Дмитрий Ермак в телесериале «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 13.25 «Лучшие из лучших» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.00, 12.45, 15.30, 20.55 Новости
07.05, 12.50, 15.35, 18.45, 21.00, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.25, 02.35 Специальный репортаж 12+
10.25 Бокс. Чемпионат мира. Мужчины. Трансляция из Узбекистана 0+
11.20, 01.30 «Шинная борьба». Документальный сериал. 1-я серия 16+
13.55 Хоккей на траве. Кубок России. Женщины. Финал. Прямая трансляция из Казани
16.25 Хоккей. Лига Ставок Большой тур Сборной. Россия – Белоруссия. Прямая трансляция из Челябинска
18.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. Финал. «Динамо» (Москва) – «Локомотив» (Калининградская область). Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Удинезе» – «Наполи». Прямая трансляция
00.30 Смешанные единоборства. UFC. Генри Сехудо. Лучшее 16+

НТВ
04.45 Сериал «ПЛЯЖ» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00, 00.00 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Денис Никифоров в детективном сериале «БИМ» (S) 16+
22.15 Премьера. «Спасибо, родная…» Песни Виктора Резникова (S) 12+
00.20 Сергей Маховиков, Лянка Грыу, Александр Тютин в остросюжетном сериале «БЫВШИХ НЕ БЫВАЕТ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.45 «Давай разведемся!» 16+
08.45 «Тест на отцовство» 16+
10.30 «Забота о важном» 12+
10.35 «Тест на отцовство» 16+
10.55 «Понять. Простить» 16+
12.10 «Порча». «Дарица» 16+
12.40 «Знахарка» 16+
13.15 «Верну любимого» 16+
13.30 «Забота о важном» 12+
13.35 «Верну любимого» 16+
13.55 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 «СЛАБОЕ ЗВЕНО» 16+
19.00 «ПРОЗРЕНИЕ» 16+
23.25 «МЫШЕЛОВКА НА ТРИ ПЕРСОНЫ» 16+

ЗВЕЗДА
05.00 «КЛАССНЫЕ ИГРЫ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.10 «ПРИКАЗ: ОГОНЬ НЕ ОТКРЫВАТЬ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
13.45, 15.05 «СЛЕД ПИРАНЬИ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Вторая мировая: пламя и сталь». Документальный сериал «Автоматическое оружие. Пистолеты-пулеметы» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ПРОЩАНИЕ СЛАВЯНКИ» 12+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүгә һәм дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәчесе **Ситдыйков** Мөслих Мансур улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүгә һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татэнергосбыт» акционер җәмгыяте директоры **Сөләйманов** Рифнур Хәйдәр улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә зур өлеш кертүләре өчен тыл хезмәтчәннәре: **Тукаева** Рәшидә Садри кызы, **Ходарина** Ольга Михайловна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Россия почтасы» акционер җәмгыяте «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсенең Зәй почтамты 423350 Сарман почта элемтәсе бүлекчәсе башлыгы **Шәрипова** Әлфия Хәмидулла кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе метрополитенда полиция бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Хәйруллин** Айрат Галимулла улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Казан шәһәре «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесенең Советлар Союзы Герое И.К. Кабушкин исемендәге трамвай депосы трамвай йөртүчесе **Соболева** Екатерина Михайловнага **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы советы аппаратының бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге башлыгы **Гафурова** Лилия Рәшит кызына, «Связьинвестнефтехим» акционер җәмгыяте баш бухгалтеры **Мәхмүтов** Илдус Фатыйх улына, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең контроль-хисап палатасы рәисе **Нургалиев** Илнар Мөнир улына, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Финанс идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары **Хайрулина** Татьяна Салихзян кызына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратның икътисадый идарәсе операцияләрне планлаштыру һәм бизнес анализлау идарәсе башлыгы урынбасары **Орлова** Инна Геннадьевнага, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте баш бухгалтеры – җәмгыятьнең генераль директоры каршындагы башкарма аппаратның бухгалтерлык исәбе һәм хисабы идарәсе башлыгы урынбасары **Цыганова** Татьяна Викторовнага, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Югары бизнес мәктәбе доценты **Салихов** Ирек Фәрит улына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясенең
27 апрель, 2023 ел, № 15/110 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы Балтач районы территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кабул итү турында хәбәре

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 22, 26 һәм 29 статьяларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 15 һәм 18 статьяларына таянып, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Балтач районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләренең туктатылуына бәйле рәвештә, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Балтач районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзасын билгеләү өчен, кандидатура буенча тәкъдимнәр кабул итү турында белдерә.

Документлар 2023 елның 28 апреленнән 17 майга кадәр эш көннәрендә 9.00–18.00 сәгатьләрдә (төшке аш вакыты: 12.00–13.00 сәг.) түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420111, Казан ш., Батурин ур., 7б й. (элемтәгә керү өчен телефон: 8(843) 292-84-33).

Территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга кандидатура буенча тәкъдимнәр керткәндә, «Территориаль, округ һәм участок сайлау комиссияләрен булдыру тәртибе турында методик рекомендацияләр хакында» 15 март, 2023 ел, № 111/863-8 Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карарына таянырга кирәк. Кирәкле документлар үрнәкләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырылган.

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

БОТКА БОЗА

Һәр егерме баланың берсенең теле соң ачыла. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы белгечләре шулай дип чаң суга. Бу нәрсәгә бәйле? Баланың соң сөйләшә башлавы нәрсәсе белән куркыныч? Тел ачылуны махсус күнегүләр ярдәмендә тизләтеп буламы?

Шул сораулар белән логопед, дефектолог, нейропсихолог Гүзәл ХӘСӘНОВАга мөрәҗәгать иттек.

:: Теле соң ачылган балалар саны соңгы арада нишләп шулкадәр күбәйде икән?

– Дөрестән дә, соңгы арада андый балалар саны арттканнан-арта бара. Моңа гаҗәпләнәсе дә юк кебек. Ишерен-батырын түгел: бүген балаларны ата-анадан бигрәк «You Tube»тагы видео геройлары тәрбияли. Балалар шулар белән «аралаша», аларның үз-үзен тотышын кабатлый. Әлеге геройларның сөйләменнән исә кайчак чәчләр үрә тора. Экологиянең елданел начарлана баруы да эзсез югалмый. Бу да баланың үсешенә, аның сөйләменә зур йогынты ясый. Балаларның теле вакытында ачылмауга күпмедер дәрәҗәдә медицинаның алга китүе дә «гаепле». Хәзер бит җитлекмичә туган, гәүдә авырлыгы бик кечкенә булган балаларны да кеше итәләр. Бу балаларда, гадәттә, алга таба сөйләм белән проблемалар килеп чыга. Баланың теле соң ачылу нәселдән күчкән хилафлык та булырга мөмкин. Бала тапкандагы имгәнүләр, нерв системасындагы тайпылышлар да баланың вакытында сөйләшмәвенә китерә ала.

:: Баланың теле ничә яшьтә ачылырга тиеш?

– Бер яше тулганчы бала беренче сүзләрен әйтергә тиеш. 1,5 яшенә инде ул – сүзтезмәләр, 2 яше тулганчы җөмләләр белән сөйләшергә тиеш. Монда бер-ике сүздән торган гади җөмләләр турында сүз бара, билгеле. Ике яшьлек бала «Әни, су!», «Песи, мияу!» ише сүзләрне әйтә, аңлата белергә тиеш. Өч яшенә инде бала катлаулырак сүзләр, җөмләләр белән сөйләшә башлый.

:: Ир балаларның теле соңрак ачыла дигән фикер яши. Бу сүзләрдә хаклык бармы?

– Кыз һәм ир балаларның кайсының теле тизрәк ачылуны дәлилләгән фәнни аңлатмалар юк. Ә менә кызларның малайларга караганда тизрәк өлгерүе күптән билгеле. Кыз бала малайга караганда дүрт ай алданрак үрмәли, йөри, сөйләшә башлый. Әмма бу кызлар малайлардан акыллырак дигән сүз түгел. Кыз баланың баш мие уң һәм сул ярымшарлары арасында мәгълүмат алмашы тизрәк бара. Шуңа күрә алар тизрәк өлгерә дә. Анналары алар малайларга караганда күпкә чыдамрак була. Әйтик, әгәр ани кеше йөклелек чорын авырдан уздырган икән, малайларда сәламәтлек белән проблемалар килеп чыгу ихтималы зуррак.

:: Баласының теле соң ачылуны абайлап алган ата-ана эшне нидән башларга тиеш?

– Әгәр 2,5 яшькә кадәр баланың теле ачылмаган икән, аны кичекмәстән белгечкә күрсәтергә кирәк. Иң беренче чиратта, ата-ана неврологка мөрәҗәгать итәргә тиеш. Дөрес, баланың теле соң ачылачакны иртәрәк тә абайлап була. Әгәр бер яше тулган бала күзгә туры карый алмаса, исемен әйтүгә борылып карамаса, кичекмәстән белгечкә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Баланың теле вакытында ачылмау нәрсәсе белән куркыныч?

– Соң сөйләшә башлаган баланың киләчәктә яшьтәшләре белән аралашканда проблемалары килеп чыгарга мөмкин. Мәктәпкә әзерлек чорында да кыенлыклар күзәтелә. Соң сөйләшә башлаган бала еш кына начар укый. Бигрәк тә тел фәннәрен авырдан үзләштерә. Грамматика, дөрес язу, ишеткәнне истә калдыру сәләте дә «аксый».

:: Баланың теле вакытында ачылсын өчен нәрсәләрне истә тотарга кирәк?

– Сабыегыз дөньяга аваз салган беренче көннән үк аның белән сөйләшегез. Кечкенә чакта әби-бабайларыгыз сезнең белән ничек сөйләшә иде, хәтерлисезме? Бала белән аралашканда сезнең сөйләмегез дә әнә шундый хис-тойгыларга бай булырга тиеш. Бала белән аралашканда кыска-кыска җөмләләр белән сөйләшегез, сүзләрегезне аермачык, төгәл итеп әйтегез. Һәрчак баланың күзенә карап сөйләшегез. Аның ымнарын, сөйләмен дә игътибар белән тыңлагыз. Саф һавада йөргәндә балага тирә-юньдәге һәр нәрсәне күрсәтеп, аңлатып барыгыз. Балагыз һәрчак хәрәкәттә булсын. Аның эре һәм вак моторика үсешен дә һәрчак контрольдә тотыгыз.

vk.com

БАЛАНЫҢ ТЕЛЕ СОҢ АЧЫЛУНЫ КИСӘТӘ ТОРГАН ЫСУЛЛАР

✓ Түбәндәге уенның шифасы тими калмас. Бала авызының бер читенә печенье куегыз да аңа шуны тел белән «куып тотарга» кушыгыз. Бу күнегүне даими рәвештә кабатлап торырга кирәк.
✓ Бала телен тышка чыгарсын да, шуның өстенә янә бер печенье кисәге куегыз. Ул, телен селкетмичә, шуны берничә секунд дәвамында телендә тотып торырга тиеш.
✓ Балага гел ботка сыман сыек ризык кына ашатырга ярамый. Ул ризыкны яхшылап чәйнәргә дә тиеш. Ул чакта аның барлык мускуллары хәрәкәткә киләчәк. Бу исә, үз чиратында, аның сөйләменә дә уңай йогынты ясаячак.
✓ Теле соң ачылган балага туңдырманы ялап ашау, йогыртлы тәлинкәне ялап кую да файдага булачак.

Абау!

Каһвә белән чәй коткара

Каhвә һәм чәй эчү инсульттан саклый. Кытайның Тяньцзинь медицина университеты галимнәре шулай дип ышандыра. Алар уздырган тикшеренүдә 365682 кеше катнашкан. Белгечләр аларны 2006 елдан башлап, 14 ел дәвамында күзәткән. Тикшеренүдә кытайлар никадәр каһвә яисә чәй эчүләрен сөйләгән. 14 ел эчендә тәҗрибәдә катнашкан 5079 катнашучыда деменция барлыкка килгән, 10053 кешене инсульт суккан. Җыелган мәгълүматларны анализлап, галимнәр көненә 2–3 чынаяк каһвә яисә 3–5 чынаяк чәй эчүче кешеләр инсульт яисә акыл зәгыйфьлегеннән сирәгрәк интегә, дигән нәтиҗәгә килгән. Аларга инсульт ихтималы – 32 процентка, деменция авыруы барлыкка килү куркынычы 28 процентка азрак яный икән.

Шифасы булсын!

КАН ТАМЫРЛАРЫ КИҢӘЙСӘ...

Помидор. Пешкән помидорны кисәкләп тургагыз да киңәйгән аяк тамырларына каплап, чеметкәли башлаганчы тотыгыз. Помидорларны алгач, аякларны салкын су белән чайкап куярга онытмагыз. Дәвалану процедурасын тамыр зәңгәрлеге беткәнче эшләргә кирәк.

Әрем. Бер уч төелгән әрем яфрагы белән орлыгын ярты литр оеган сөткә салып болгатыгыз. Шул боламыкны 3–4 кат марлядан ясалган салфеткага сылап, аякның киңәйгән тамырларына каплагыз. Өстенә полиэтилен ябыгыз да, аякны кечкенә мендәргә сузып куеп, ярты сәгать утырыгыз.

Бу – кызык!

Кара кулына

Кешенең холкын, рухи торышын беләсең килсә, кулына кара, ди психологлар.

▸ Төшенкелеккә еш бирелүче кешеләрнең куллары аксыл, ә кызу табигатьлеләрнеке кызыл була. Гадәттә, авыр рухи кичерешләрдән соң кешенең куллары дымланучан һәм салкын була, ди белгечләр.
▸ Кулларыгыз даими салкын тора икән, сездә анемия, гипотония, йөрәк чирләре булырга мөмкин.
▸ Дымлы куллар организм өчен кирәкле матдәләр бүлеп чыгаручы бизләрнең сәламәт булмавын күрсәтә. Шулай ук хис-кичерешләр тотрыксызлыгына да ишарә ясыйлар.
▸ Кызыл куллар – сездә, мөгаен, кан басымы югары. Матдәләр бүлүче бизләрнең дә дөрес эшләмәве ихтимал.
▸ Кул рәвеше: кулның формасын үзгәртеп булмый. Ләкин дөрес һәм җентекләп тәрбияләгән вакытта, сез кулларыгызны нәфисрәк итә, аларны матурландыра һәм дөресрәк форма бирә аласыз.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

ТИРЕС УРЫНЫНА – КЫЧЫТКАН

Быел яз иртәләгәч, бакчада башкарыла торган эшләр дә иртәләде. Журналист, бакчачы блогер Роза НУРГАЛИЕВА тәрәзә төпләрендәге «байлыгы»н теплицага күчерергә дә өлгергән. «Шаулап үсеп утыралар», – ди ул. Помидор, борыч һәм кыяр күчерү буенча укучыларга киңәшләрен дә бирде.

:: Роза, үсентеләрне бакчага күчереп тә өлгергәнсез. Кичке салкыннар куркыныч түгелме соң әле?

– Помидор, борыч, кыяр үсентеләрен теплицага күчердем, әйбәт кенә тернәкләнеп яталар. Шулай да төнгә спанбонд белән каплыйм, акрынлап кына ияләштерәм.

:: Ел саен башкара торган эш булса да, һәр бакчачының еллар буе сыналган үз сере була. Ә менә сез помидор, борыч, кыяр үсентеләрен ничек утыртасыз?

– Теплицаның туфрагында чир чыганаклары калмасын өчен иң элек «Фитоспорин» эремәсе сибәм. Чокырына 1 аш кашыгы исәбеннән «Оргавит» салам. «Оргавит» – шул ук тирес, әмма зарарлы микроорганизмнардан чистартылган, исе юк диярлек, гранула формасында. Ул акрынлап таркала, үсемлекне ашлый. Тагын берәр төймә «Глиокладин» салам. Монысы тамыр череге чирләреннән саклау өчен. Бер капта –100 төймә, без, гадәттә, шуның кадәр үсенте утыртабыз да инде.

:: Үсентеләр төбенә кычыткан салып утыртучылар да бар.

– Чокырына ваклап кычыткан салганым бар. Быел яз иртә килде, әлегә кычыткан

vk.com

кечкенә. Бакчага күчергәндә кычыткан да салачакмын. Соңрак, үсентеләр тернәкләнеп киткәч, әчетеп сибәм. Мичкәнең өчтән бере кадәр кычыткан, тузганак салам, 1 литрлы банка белән көл өстим, су агызып, 5–6 көн әчетәм. Аннан 10 л суга 1 л әчетке кушып сибәм. Тирес бик кыйммәт бит, машинасы 10 мең сумнан ким түгел, ә кычыткан белән тузганак бөтен җирдә үсә.

:: Утыртканнан соң 10 көн су сипмәсәң дә ярый, ди кайбер бакчачылар.

– Күчергәндә чокырына су сибеп утыртам. Алай ун көн сипми торганым юк. Җире кибүгә карап су сибелә инде.

Белеп тор!

Җиләккә хәл кертәбез

Бакча җиләген тукландыру буенча ***Рәмзия Әхмәдуллина*** *киңәше*

Кыш чыккан җиләкләрнең иске, авыру яфракларын кисеп, төпләрен йомшартып чыгабыз. Аралары киңрәк булса, көрәк очы белән генә казып чыгарга да була. Әйбәтләп су сибәбез. Аннары мондый сыек катнашма әзерлибез: 10 л суга 0,5 чәй кашыгы бор кислотасы (кайнар суда эретеп салына), 0,5 чәй кашыгыннан кимрәк итеп сыек марганцовка, 15 тамчы йод, 2 аш кашыгы нашатырь спирты салып болгатабыз.

Болгаткач, дымлы җиләк төпләренә 0,4 л салып чыгабыз. Бу сыек ашлама җиләкләргә яшәү көче бирә, хәл кертә. Җиләк уңышын бермә-бер арттыра. Шуның өстенә көл сибеп куйсагыз, тагын да шәп!

Тәмле булсын!

Гәрчичле шашлык

Айнур Гарипов рецепты

Кирәк: *2 кг тавык, бәрән яки бозау ите, 2 баш суган, 1–2 аш кашыгы соя соусы, шашлык өчен тәмләткеч, 1 банка (250 г) гәрчич.*

Әзерләү: туралган итне суган, гәрчич, соя соусы һәм тәмләткеч салып болгатырга һәм салкынча урында 2 сәгать тотарга. Мондый шашлык бик тәмле һәм сусыл була. Яшел тәмләткечләр һәм бәрәңге белән табынга бирергә.

Вак бәлеш

Камыр өчен кирәк: *1 стакан сөт, 1 стакан су, 100 г атланмай, 1 аш кашыгы үсемлек мае, 1 чәй кашыгы көпшәкләндергеч, тоз, шикәр комы, он салып, йомшак кына итеп камыр басабыз. Аны ял иттерәбез.*

Эчлек өчен кирәк: *бәрәңге, суган, ит, тоз, борыч.*

Вак бәлешләр ясыйбыз. Йөзе килгәч, бөкеләрен ачып, эченә кайнар шулпа салабыз да, яңадан ябып, 20–25 минутка духовкага куябыз.

(«Татар ядкарьләре» төркеменнән)

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

Исеңдә тот!

Зыяны күбрәк

Бер яктан караганда, кырмыскалар файдалы. Чөнки алар зарарлы бөҗәкләрнең личинкаларын юк итәләр. Туфракның уңдырышлы өлешендә оя ясап, үсемлек тамырына кислород килүгә, уңыш артуга да сәбәпче булалар.

Икенче яктан, алар – бакчага телә алып кайтып, үсемлекләрне юк итүче дә. Телә белән кырмысканы агылый белән тагылый дияргә дә була. Алар – табигатьтәге иң шәп симбиоз үрнәге. Кырмыска теләдәге баллы секрет белән туклана, ә тегесе кырмыска ярдәмендә бер үсемлектән икенчесенә күчә. Шуңа күрә кырмысканы яхшы һәм начарлар рәтенә кертүне үзегез карагыз.

Ә менә бакчагызны бөтенләй кырмыска басмасын дисәгез, казылмаган җирләрне калдырмагыз, җиләк-җимеш бирә торган агачларның кайрыларын акшарлап, тирәләрен эшкәртеп торырга кирәк.

Кырмыскалар бик азып китсәләр, «Муравьед» дигән препарат кулланырга була. Ул порошок сыман, 1 кабын 10 л суга салып, кырмыска баскан урыннарга сибәсе. Шулай ук әлеге препаратның «Мурацид» дигән аналогын, «Гром – 2» препаратын кулланырга киңәш итәлә.

Керосин, сода, шикәр комына бор кислотасы кушып болгатылган катнашма да – кырмыскаларга каршы яхшы чара. Шулай ук аларга каршы кайнап торган су һәм көл сибәргә мөмкин.

Укучы киңәше

ГӘРЧИЧ ЧӘЧСӘҢ, УҢАСЫҢ

Мин бакчамның бер генә җирен дә буш тотмыйм, гәрчич чәчәм. Ак гәрчич – бик тиз үсә торган берьеллык үсемлек. Ул туфракны азот, калий һәм фосфорга баета. Ул яктылык һәм дым ярата. Аның тамырларында күкерт бик күп, шунлыктан аючикерткә, май коңгызы, каты корт (проволочник) гәрчич үскән урыннарны яратмый.

Гәрчич тамыр череге һәм фитофторага каршы да көрәш чарасы булып тора. Туфракны сәламәтләндерү өчен бер сутый җиргә 400 г чамасы гәрчич кирәк.

Чәчкәннән соң, 40 көн үткәч, чәчәк атканчы аны чабып алырга кирәк.

Әлеге седерат утыртылган җиргә кәбестә белән редистан кала теләсә нинди яшелчә утыртырга була.

Гайшә ӘҮХӘДИЕВА.
Арча

Хуҗабикәгә

ЧИКЛӘВЕКНЕ СУЫТКЫЧТА САКЛА

Кабыгыннан чистартылган чикләвекләрне суыткычның түндыра торган өлешендә саклагыз. Болай ул файдалы үзлекләрен озаграк саклый, исе һәм тәме озак вакыт үзгәрми. Чикләвекләрне герметик савытка кыздырмыйча, чи килеш салып куярга кирәк. Гадәти бүлмә температурасында сакланган чикләвекләргә бераздан әчкелт тәм керә, ә болай саклаганда тәме элеккечә калачак.

ЧУЕН ТАБАГА ТОЗ КИРӘК

Чуен таба искергәч, күгәрекләр барлыкка килмәсен дисәгез, аны гадәти юа торган чаралар белән түгел, ә тоз белән ышкыгыз. Тоз табаны чистартып кына калмыйча, ашарга әзерләгәндә сеңгән ризык исен дә бетерә.

ИСНЕ ЛИМОН БЕТЕРӘ

Кулдан килгән суган һәм сарымсак исен бетерү өчен, лимон белән сода кулланыгыз. Аларны кулга сөртеп, суда чайкап кына аласы гына, исең эзе дә калмаячак.

«БИСМИЛЛА»ДАН БАШЛЫЙСЫ

Динебездә чисталыкка аеруча зур игътибар бирелә. Мөселман кеше күңелен, җанын, тәнен генә түгел, торган җирен, йорт тирәсен дә чисталыкта тотарга тырыша. Пәйгамбәребез Мөхәммәд мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу хакта бер хәдисендә: «Аллаһ матур һәм матурлыкны ярата, Аллаһ юмарт һәм юмартларны ярата, Аллаһ киң күңелле һәм киң күңеллеләрне ярата, Аллаһ чиста һәм чисталарны ярата. Шулай булгач, йорт тирәләрегезне чистартыгыз...» – дигән. Моның билгеле бер тәртибе бармы? Өй юганда нәрсәләрне истә тотарга кирәк?



Бу сорауларыбызга «Саләх» мәчете имам-хатыйбы Тимергали хәзрәт ЮЛДАШЕВ ачыклык кертте.

:: Тимергали хәзрәт, иң элек исламда чисталык мәсьәләсенә тукталыйк әле.

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Чисталык ул – иманнан», – дигән. Аллаһы Тәгалә Корьәни Кәримдә дә күп кенә аятьләрдә чисталык турында әйтә. Динебездә чисталыкка бик зур урын бирелгән. Биш вакыт намаз укыр алдыннан тәһарәт алу да – чисталык билгесе. Моннан тыш мөселманның кигән киеме дә, намаз укыган урыны да чиста булырга тиеш. Кирәк булганда госел алу, мунча керү – болар бар да динебезнең асылы.

:: Өйне ишек төбеннән түгел, түр башыннан юа башларга кирәк, диләр. Бу нәрсәгә бәйле?

– Пәйгамбәребез һәр эшне дә «бисмилла» әйтеп башларга кушкан. Бу очракта да иң беренче таләп шул. Аннары пәйгамбәребез һәр эшне уң яктан башларга яраткан. Димәк, өй юуны да уң яктан башларга кирәк. Динебездә өйне ишек төбеннән түгел, түр башыннан юа башларга кирәк дигән таләп юк. Әгәр ул кайсыдыр районда, җирлектә гадәт булып кергән икән, шулай эшләсеннәр. Әмма бу таләпне бозуның берниндн зыяны да, гөнаһы да юк.

:: Җомга көнне өй җыештырырга ярыймы? Гает көнне рөхсәт ителәме?

– Җомга – Аллаһы Тәгалә көннәренең берсе. Ул иң хәерле көннәрдән санала. Җомга хәтта гает көненнән дә хәерлерәк. Бу көнне гыйбадәт белән үткәрү хәерле. Ләкин җомга көнне эш башкару, гамәл кылу, шулай ук өй юу да шәригатькә һич кенә дә каршы килми. Бу көнне җомга намазы вакытында гына эш эшләргә ярамый. Ирләр бу вакытта – җомга намазында, гает көнне гает намазында булырга тиеш. Гаеттән һәм җомгадан соң кеше үзе теләгән теләсә кайсы эшкә керешә ала. Өй эчендә башкара торган эшме бу, әллә инде урамда, ишегалдында эшли торганымы – анысы мөһим түгел.

:: Кояш баегач, идән юган суны түгәргә ярамый, диләр. Бу сүзләрдә хаклык бармы?

– Ә бу суны кая куясың соң? Аны түгәргә кирәк бит инде. Кичен мунча кергән суыбыз да шул ук җир астына китә. Шуңа күрә кояш баегач, идән юган суны, «бисмилла»ны әйтеп, кеше йөрми торган урынга түгәргә кирәк. Монда берниндн каршылык юк.

:: Кояш баегач, тузан сөртергә, өй җыештырырга ярыймы?

– Әйе, тузан сөртү, өй җыештыру кебек эшләрне кояш баегач та башкарырга рөхсәт ителә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ИСЛАМДА ЧИСТАЛЫКНЫҢ 7 КАГЫЙДӘСЕ

Кулның чисталыгы. Узеңнеке булмаган әйберләрне алмау һәм байлыкның кырыктан бер өлешен мохтаҗларга бирү, гади генә әйткәндә, сәдака биреп ярдәм итүдә саран булмау.
Колакларның чисталыгы. Гайбәт, фетнә һәм дошманлыкка чакыручы сүзләрне тыңламау.
Күзләрнең чисталыгы. Кешеләргә хөсетлек, бозыклык һәм вәсвәсә белән карамау.
Авызның чисталыгы. Буш сүздән, гайбәттән һәм чиктән чыгып күп сөйләүдән тыелу. «Сөйләшү көмеш булса, сөйләшмәү – алтын», – ди халык.
Тәннең, киемнең һәм яшәгән урынның чиста һәм пөхтә булуы.
Уй һәм фикернең чиста булуы. Гөнаһлы фикерләргә юл куймау. Бигрәк тә кешеләр турында тиешсез начар уйламау.
Йөрәкнең чиста булуы. Кәферлек, монафыйклык, тәкәбберлек һәм хөсетлек чирләреннән пакь булу.

Май аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Дүш	00:45	04:01	16:52	19:21	21:45
2	Сиш	00:37	03:59	16:53	19:23	21:49
3	Чәрш	00:28	03:56	16:54	19:25	21:53
Казан кызы Аделина Гобәйдуллина 2021 елның августында кияүгә чыга. Туй көненә ярты ел алдан әзерләнә башлыйлар. Классик-романтик мәхәббәт тантанасы оештыра алар. Мәҗлес өчен «Ривьера» комплексын сайлыйлар. Гаилә бәйрәмен 700–800 мең сумга үткәрәләр. Мөмкин булганча, акчаны янга калдырырга тырыштык, ди кичәге кәләш. Туй оештырганда нәрсәләргә игътибар итәргә икәнне сораштык аннан.

– Иң мөһиме – ресторанга вакытында бронь салу иде. Аннан инде – фотограф. Минемчә, фотографка акча җәлләргә һич ярамый. Аның иҗади эшләрен карап чыгарга кирәк. 100 процент ошатсагыз гына шул фотографны чакырыгыз. Соңыннан фотосурәтләргә карап аптырарлык булмасын. Видеограф та бик мөһим. Әмма хәзерге көндә, минемчә, кыска гына видеоролик монтажлауны һәркем булдыра. Күпләр хәтта телефонга гына да төшерә. Мәҗлесне алып баручы кешегә дә акча җәлләргә кирәкми. Социаль челтәрләргә ышанмадык, бу очракта шәхсән үзебез белгән кешеләрнең киңәшләренә колак салдык, – дип сөйләде Аделина. – Туй мәҗлесендә декорацияләргә дә игътибар бирергә кирәк. Декораторлар белән шәхсән очрашырга, эскизлар сызарга, теләкләрне җиткерергә. Декор өчен шактый акча чыгарып салырга әзер булыгыз. Безнең туйда, мәсәлән, бизәлеш буларак та чын чәчәкләр кулланылды. Ә андый декорация бик кыйммәткә чыга. Туйда ут куючының эше дә бик әһәмиятле. Ул антураж тудыра! Кыскасы, һәр вак нәрсә өчен дә түләргә әзер булырга кирәк. Туй мохите әнә шулардан җыела да инде.

Аделинаның туенда кунаклар өчен бүләкләр дә каралган. «Махсус рәссам чакырдык. Тантана башланыр алдыннан, ул кунакларның сурәтләрен ясады. Моннан тыш, аш-су менюсын өстәлләргә куйдык. Һәрбер кунак ризыклар белән таныша торсын, составын өйрәнсен өчен кирәк дип таптык моны», – ди әңгәмәдәш.

Туй көнендә, билгеле, кызлар кабатланмас һәм иң гүзәл кәләш булу турында хыялллана. Моның өчен матур күлмәк кирәк. Аделина аны шулай ук ярты ел алдан эзли башлаган икән. «Эзләнүләремнең беренче көнендә үк таптым мин аны. Берне генә дә түгел, икене! Кызларга да киңәшем шул: төрле бәягә һәм төрле рәвештәге күлмәкләр тәкъдим иткән салонга барсыннар иде», – диде ул.

Классик туй кызык түгел?!

Нәҗип Җиһанов исемендәге консерватория студенты Гөлназ Гарифуллина классик туйдан читләшергә булган. Ире белән гаилә бәйрәмен коттедж арендалап үткәрергә җыеналар.

– Яшьләрчә, кәттә мәҗлес оештырырга теләдек. Теркәлү тантанасы тар даирәдә – гаилә, якыннар янәшәсендә генә узачак. Икенче көнне исә «туй кичәсе» көтелә. Анда 35 яшькә кадәр туганнар һәм дус-ишләр булачак. Әби-бабай, әти-әниләр, апа-абыйларсыз! Берәү дә оялмасын, чын күңелдән ял итсен, дип теләдек. Шуңа күрә туй коттеджда узачак, – ди әңгәмәдәш.

Йортның зурын, барлык уңайлыклары булганын эзлиләр. Куна калырга теләк белдерүчеләр булса, аларга да урын булачак икән. Коттедж хуҗасы белән килешү төзегәннәр инде.

– Коттедж булгач, банкет өлешен кейтеринг хезмәтенә тапшырабыз. Алар белән дә килешү төзеп куйдык инде, – ди Гөлназ. – Туй күлмәге дигәннән, баштан ук, купшы итеп киенмибез, дип килешкән идек. Тик… Кызык өчен генә туй күлмәкләре салонына кергән идек, кием-салымнар сатып алып чыктык. Әмма без аны язылышу вакытында гына киячәкбез. Коттеджагы мәҗлестә иркенрәк киемнән булачакбыз.

Фотограф, видеограф хезмәтен таныш-белешләре күрсәтәчәк икән. Коттеджагы чарага исә аларны яллап торуны кирәк дип тапмаганнар. Яшьләрнең телефоннары яхшы бит хәзер.

– Чакыру кәгазьләрен видео рәвешендә ясадык. Бик матур килеп чыкты! Туйның төсен, кайда узасын – барлык нечкәлекләрен дә күрсәттек. Фотозона да таптык. «Авито» ярдәмгә килде. Тамада белән дә килештек. Гомумән, төп эшләрне башкардык бугай инде. Туйга ярты ел алдан әзерләнә башлаган идек. Әле менә визажист, кондитер табасы калды. Сүз дә юк, дулкынлану бар. Әмма борчылудан битәр күбрәк куанасың икән. Бу – рәхәт мәшәкатьләр, – ди кәләш.

«Иң рәхәте – аек кунак белән эшләү»

Алып баручы Рамил Шәрәфиев мәҗлесләр үткәрү өлкәсендә 2014 елдан бирле эшли. Туйларның төрлесен күргән кеше.

– Шундый бер гадәтем бар: һәрбер алып барган туйны ноутбукта теркәп калдыра башладым. Нинди уеннар үткәргәнмен, нинди кызык-мызыклар булган. Ел саен 70–80 мәҗлес килеп чыга икән, – ди Рамил. – Якынча 600ләп мәҗлес алып барганмын. Әле бу теркәлгәннәре генә. Шулардан чыгып, яшьләрнең нәрсәгә игътибар итүен чамалый алам.

Рамил әйтүенчә, яшьләрнең күбесе мәҗлес узасы залга, аның матурлыгына игътибар итә. Залның популярлыгы роль уйный, ди тамада. Артистлар чакыру, алып баручылар да мөһим. «Сарафан радиосы» әле дә эшли дигән фикердә ул. Хәзер инде фотограф-видеографларның да иң популярларын эзлиләр.

Рамил Шәрәфиев әйтүенчә, өйдә уза торган мәҗлесләрне дә сафтан төшереп калдырырга ярамый. Алар булган, бар һәм булачак.

– Мондый бәйрәмнәрне кафе-рестораннарда уза торганнар «каплый». Алар күренми генә. Үзенә күрә бер романтикасы бар аның, – ди ул. – Миңа да еш кына андый тәкъдимнәр килә. Әмма андый заказларны алмыйбыз шул. Өйгә банкет залындагы тулы бәяне куя алмыйбыз. Аннан, өйдә уза торган мәҗлесләрдә безгә әллә ни эш калмый.

Рамил Шәрәфиев сүзләренчә, хәзер яшь парлар купшылык артыннан кумый. «Хәләл индустриягә күчкәч, шуны аңладым: күпләр никах кына үткәрә яисә никах туйлары ясый. Тренд кына түгел бу. Кешенең акылы, фикере үзгәрә. Хәмер ягыннан карыйк: беренчедән, дин буенча – тыелган гамәл, икенчедән, туйга дип хәмер эчемлекләрен күп итеп алалар, әмма аны ул кадәр күпләп кулланучы булмый. Күбесе рульдә килә, кемнендер эшкә барасы бар. Аек тамашачы белән эшләү – иң рәхәте. Алар син сөйләгәнне анализлый белә».

«Асылы югала»

Инструменталист, тамада Илмир Ямалов мәҗлесләр алып бару өлкәсендә – 12 ел. «Кунаклар – иң мөһим кешеләр» дигән шигарь белән эшли ул. Туйларны күп күргәч, чагыштырырлыгы да бар, димәк.

– Кызганыч, хәзер яшьләрнең күбесе шоу-программага, туй асылын җуеп, концертка күбрәк басым ясый. Алып баручы да – халык белән эшләүче түгел, концерт номерларын игълан итүчегә әйләнеп кала, – ди Илмир. – Юбилей, корпоративтан аерылсын өчен, программага туй элементлары кертергә тырышалар. Әйтик, парларны ансамбль каршы ала, бал-май каптыру күренеше, кочмә язылышу һәм башкасы. Яшьләр хәзер йә алданрак, йә туйдан соң да язылыша. «Әче» дип кычкыру, үбештерү юк, кунакларга сүз бирү юк, әти-әни, туганнар котлый. Фотосессия вакытында кунаклардан конверт җыеп алсалар, шул җиткән. Без уздырган туйларның 70–80 процентында шулай.

Туйлар европалаша, ди алып баручы. Билгеле булганча, анда туйлар фуршет рәвешендә бара, кияү белән кәләш рәхмәт сүзе әйтә, ата-аналар котлавы була.

– Бездә дә шулай эшләргә тырышалар. Туй заманасына күрә үзгәрә. Һәрбер алып баручының – үз эшләү стиле, әмма мин яшьләргә туйның асылын тәшкил иткән кайбер нәрсәләрне калдырырга киңәш итәм. Шул ук йолаларны. Миңа, фольклорчы буларак, моны аңлату җиңел. Ул йолаларны бик кызык итеп эшләргә була. Милли дә, заманча да эшләсәк, яшьләргә дә ярыйсың, традицияләр дә югалмый, – ди Илмир Ямалов.

Урыны-урыны белән туй мәҗлесләре аерыла, ди ул.

– Казанда бөтенләй башка төрле туйлар. Татарстан районнарында әле азмы-күпме йолалар саклана. Ә төбәкләрне әйткән дә юк, – дип сөйләде Илмир. – Ульян, Пенза, Башкортстан, Самара якларына күп йөрибез. «Килен кульяулыгы сату», такмаклар җырлаулар, подноста килен биетү – менә шундый йолалар сакланган анда. Яңалык ул – күптән онытылган искелек. Аларны торгызып эшләү бик кызык.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

НИЧЕК АЗРАК ТОТАРГА?

Финанс белгече Ләйсән Халиковадан, туй мәҗлесенә әзерләнгәндә акчаны ничек артык сарыф итмәскә, дип сораштык.

✓ Туй чыгымнары – нигезсезрәк чыгымнар. Туйдан соң да тормыш бар бит әле: машина, ремонт, ял итү теләге. Никахны зурлап, туйны тыйнаграк итеп үткәрергә мөмкин.

✓ ЗАГСтан соң иң якын дус-ишләр белән кафеда утырырга мөмкин. Зурлап туй уздырып, хәзер кешене шаккатырып булмый. Кеше шаккатырам дип үткәргән туй – зур хата.

✓ Чыгымнарны киметәм дисәң, сатып аласы әйберләрне арендага алып торырга мөмкин. Хәзер фотограф-видеографсыз да сыйфатлы фото-видеолар ясарга була, замана телефоннары яхшы. Хәзер гаеп итү дигән нәрсә бик юк, шуңа күрә 100 кунак урынына иң якын кешеләрне генә чакырырга да була.



БАЛАСЫН ЮГАЛТКАН САДЫЙКОВЛАР:

«КӨТЕГЕЗ», – ДИП ТӨШКӘ КЕРДЕ»

Болай булыр димәгән идек. Аксубайда яшәүче Евгения һәм Рамил Садыйковлар гаиләсенә моннан бер ел элек зур хәсрәт килә. Килешү буенча хезмәт итүче уллары Руслан вафат була. Бер ел вакыт узып китсә дә, яралар һаман яңа. Уйлаган саен йөрәк әрни, ди Рамил.

– Хатыным белән Лубян урман-техник көллиятендә укыганда таныштык. Удмурт кызы ул. Дүртенче курста гаилә кордык, шуннан соң Русланыбыз туды. Улыбыз да тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, без укыган көллияткә керде. Укуын укыды, тик эшли алмады. Уку йортын тәмамлауга армиягә барыр вакыты җиткән иде, – дип сөйли Рамил.

Егет алдында йә бер елга армиягә бару, йә инде контракт нигезендә хезмәт итү мөмкинлеге була. Ул ике дә уйламыйча, килешү төзи. 2021 елның 1 августы була бу. Ул чакта илнең тыныч чагы. Руслан Севастопольдә хезмәт итә. Диңгезчеләр пехотасында өлкән майор. 2021 елның декабрендә көчле егетләрне бер частька берләштерә башлыйлар.

Рамил Садыйковның шәхси архивыннан

– Улыбыз 30 декабрьдә ялга кайтып китте. Китүгә, без – хәрби өйрәнүләрдә, дип хәбәр итте. Шулчак күңелгә борчу керде. Яңалыклардан да күрсәтелгән бит. Үзем дә армиядә хезмәт иткән, ике ел урманчы булып эшләп, аннан хокук саклау өлкәсендә эшләгән кеше буларак, барысын да сиздем. Ниләр булып бетәсен аңлаган идем. Әмма балабызны югалтырбыз дигән уй булмады, – ди Рамил.

Руслан үзе дә сер бирми. Әтиәнисен борчымас өчен, гел шалтыратып тормый. Сөйләшсә дә, бар да яхшы, дип кенә җавап бирә. 21 февральдә махсус хәрби операциягә кертүләрен хәбәр итә. 5 мартта көтеп алынган телефон шалтырый. Ул чакта да Руслан, бар да яхшы, дип кенә әйтә. 8 Мартка әнисенә чәчәк бәйләме килеп төшә. Аның эчендә: «Әни, мин сине яратам!» дигән сүзләр була. Бу чәчәкләрне Руслан беренче һәм соңгы тапкыр бүләк итә.

– Улым аз сүзле булса да, 2022 елның 9 апрелендә шалтыратканда күп сөйләште. Бөтен нәрсәне искә төшерде. Нык сагынуын, токмачлы аш ашыйсы килүен, май аенда ялга кайтырга тырышуын әйтте. Әнисе борчылып, улым, үзеңне сакла, дигәнгә, мин контрактны кеше артында качып утырыр өчен төземәдем, дип кенә җаваплады. Бернидән курыкмады. Тик, кызганыч, 20 яшендә гомере өзелде, – ди әтисе.

Русланның үлемен 12 апрельдә хәбәр итәләр. Бу көнне әниләре төш күрә. Төшендә Руслан, әни, мине көтегез, дип кайтырга җыенуын әйтә. Күп тә үтми, үлем хәбәре килә. Мина шартлаудан һәлак була. Үлгәннән соң Русланны «Батырлык өчен» медаль белән бүләклиләр.

Ә хәзер бер дә төшләренә керми икән. Газиз балаларын салкын җиргә иңдерү җиңел булмый. Ана йөрәге дә, ата йөрәге дә бик өзгәләнә.

– Әле дә авыр, – ди әтиләре. – Олы улымны җирләгәннән соң, уртанчысы Адел хәрби булырга карар кылды. Ул – Санкт-Петербург хәрби физик культура институты кадеты. Кечесе Эмиль өченче сыйныфта укый. Улларымны кыю, батыр итеп үстердек. Ир-егет Ватанын сакларга тиеш ул. Язмыштан узмыш юк, диләр. Гомере кыска булган баламның. Бик сагындыра. Тик шул вакытта горурлык та бар. Чын егет итеп үстерә алганбыз!

ЯШӘҮ ЯМЕ

Кемнедер сөендерә алу – зур бәхет. Чаллыда яшәүче Алинә Сафина шулай ди. Язмыш аны Алабугада урнашкан балалар йортына алып килә. Кыз тәрбияче булып эшли башлый. Әнә шул көн тормышын үзгәртә инде аның. Игелек юлына кереп китә ул.

Хәер, Алинә аңа кадәр дә кешеләргә карата ярдәмчел була. Ә инде ятим сабыйларны үз күзләре белән күреп, алар белән аралашканнан соң ул бөтенләй башкача уйлый, башкача яши башлый.

– Балалар йортында өч ел эшләгәч, кияүгә чыктым. Күченеп китәргә туры килде. Сабыйларны калдырып китү авыр булды. Күңелдә аларга ничек тә ярдәм итү теләге калды. Нишләргә? Кире бу эшемә әйләнеп кайтып булмый. Бик озак аптыраштa булдым. Бервакыт бер волонтер кыз белән таныштым. Ул «Чистые сердца» дигән волонтерлар оешмасында икән. Миңа шул сүз җитә калды! Ике дә уйламый аларга кушылдым, – дип сөйли Алинә.

Алинә Сафинаның шәхси архивыннан

Иң сөендергәне – бу волонтерлар ятимнәр йортларын кайгырта икән. Исемлектә Алабуганыкы да бар. Алинә җиң сызганып эшкә керешә. Сабыйларга кагылышлы нинди чаралар үтә, шунда катнаша. Тәм-томнар, пешкән ризыклар да әзерләп алып бара. Күңеленә тәңгәл килгән эш җан рәхәте бирә аңа.

– Безнең оешма сабыйларны гел сөендереп тора. Төрледән-төрле чаралар уздырабыз. Бер мәлгә булса да, ятим балаларны бәхетле итәсебез килә. Миннән генә торсамы? Барысын да әти-әниле итеп, яратып кына үстерер идем, – ди Алинә. – Чираттагы бәйрәмебезне 14 майда үткәрергә дип торабыз. Анда 130 бала булачак. Чаллы, Алабуга, Мамадыш, Түбән Кама, Менделеевск шәһәрләреннән ятимнәрне бер урынга җыеп, бәйрәм үткәрәчәкбез. Ул бик күңелле булырга охшап тора. Үз теләкләре белән ярдәм итәргә алынучылар бар. Сабыйларны чәчтарашлар матурлаячак, аниматорлар күңелләрен күтәрәчәкләр. Төрле уеннар уйнатачаклар.

Алинә бу эшенә ярдәм итеп торган якыннарына рәхмәтле. Ире дә ятимнәрнең хәлен аңлый торган кеше булып чыккан. Хәзер бергәләп эшлиләр икән. «Сабыйларны җәйгә матур итеп киендерергә ниятләп торабыз», – ди Алинә. Тик барысына да акчалары җитми. Әнә шуңа да ул изге күңелле кешеләрдән ярдәм сорый. «Әти-әни назыннан мәхрүм калган сабыйларны сөендерәсе иде», – ди ул.

Булышырга теләүчеләр өчен «Чистые сердца» волонтерлар хәрәкәте җитәкчесе Эльвира Новикова исемендәге Саклык банкы (СБЕР) картасы номеры **– 2202 2009 9649 1450**. Әлеге карта **89674601057** телефон номерына беркетелгән.

Гөлнур Мингалиеваның шәхси архивыннан

СЫЗГЫРА ТОРГАН АПА

Кама Тамагы районы Кече Мәрәтхуҗа авылында яшәүче Гөлнур Мингалиева авылдашларына бар хәбәрне сызгырып кына җиткерә. Авылга чүп җыючы машина килгәнне дә, берәр чара буласын да аның аша беләләр. Хәвеф-хәтәрләрдән дә саклап калганы бар икән.

Шушы авылга килен булып төшүенә дә 40 ел була инде. Заманында Әтнә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, эшкә җибәрелгән кызны Ринат исемле егет кияүгә алып кала. Ул вакыттан бирле инде күпме сулар аккан. Гөлнур апа авылның үз кешесенә әйләнгән. Алар Ринат абый белән өч бала үстергәннәр.

– Зоотехниклыкка укыдым. Монда килгәндә, сыер фермалары да, дуңгызныкы да гөрләп тора иде. Бик алдынгы иде алар. Мине дуңгыз фермасына эшкә билгеләделәр. Берүземә 5 мең баш иде. Шуларны көткән чакларым да булды. Шул вакытта сызгыра башладым да инде. Терлекләрне дә тыңлатырга кирәк, – ди Гөлнур апа. – Фермада 36 ел эшләдем. Зоотехниклыктан башладым, мал табибы булып пенсиягә чыктым. Рәхәт елларда эшләдем дип сөенеп торам. Үзенә күрә күңелле иде ул чаклар.

Кул эшләренә дә хирыс ул. Бер дә тик торганы юк икән. Мунчала үрә, урындык япмалары бәйли. Мәдәният йортына да йөри, концерт-театрларда катнаша. Без шалтыратканда, кәрзин үреп утыруы иде. Язын талчыбык йомшак икән. Өч кәрзингә заказы бар.

– Кукмара районының Төркәш авылы кызы мин. Әтием, бик оста итеп, каз оялары үрә иде. Кечкенәдән аңа ярдәм итеп тордым. Бергә талын да җыя идек, бөктек тә. Олыгайгач, үземнең дә кәрзин үреп карыйсы килде. Инде хәзер каз оясы сораучы юк, ә менә савыт өчен кәрзин алалар әле. Язга чыккач, шулар белән мәш киләм. Тал күп. Су буеннан җыеп алып кайттым да тизрәк ясарга утырдым, – ди ул. – Зур дигәннәрен – 500 сумга, кечерәкләрен 350гә сатам. Иш янына куш дигәндәй, акчасы ярап куя. Әмма күбрәк кешеләрне сөендерергә яратам. Якыннарыма бүләккә дә таратам.

Әтисен искә алгач, Гөлнур апа туган якларын сагынып яшәвен дә әйтте. Кукмара белән Кама Тамагы арасы якын түгел. Ике елга бер булса да, ерак туганнарына, әтисенең каберенә кайтып йөриләр икән.

– Казанга 2 сәгать дигәндә барып җитәбез. Авылга кайтыр өчен 5 сәгатьләп вакыт кирәк. Көтәр кешең, туган нигезең булмагач, кайтулар сирәгәйде инде. Әмма балачак, яшьлек елларым сагындыра. Әти дә иртә китеп барды. 49ы тулмый да калды. Кәрзин үрәм дип, аякларына салкын тиде ул. Резин итек белән йөрер иде. Аягын кистеләр дә, шуннан савыга алмады. Әнине монда алып килеп карадым. Монда җирләдек тә инде. Энем Айратны да үз янына чакырдым. Шулай итеп, нигезебез калмады, – ди ул.

Гөлнур ападан җәйләрен нишләвен сорыйм. «Бакчада казынам», – ди.

Җәйләрен бакчадан тыш, Гөлнур апа авылдагы тәртипне дә саклый. Юл өстендә генә яшәгәч, күп кенә кешеләрне бәла-казадан да саклап калган. Бервакыт кечкенә генә бала, килүче машинаны күрмичә, юлга чыга. Инде бетте дигәндә, Гөлнур апа, каты итеп сызгырып җибәреп, сабыйны коткарып кала. Аның кебек итеп ирләр дә сызгыра белми икән.

– Үзләре яныма килеп, без синең кебек булдыра алмыйбыз, диләр. Нәрсәсе бар инде аның. 40 ел сызгырам, – ди ул. – Тормышны яратып яшәргә кирәк. Күңелендә тынычлык, рәхәтлек икән, бар нәрсәгә җитешәсең. Иремә рәхмәт. Ул бик акыллы булды. Ярый әле юлымда очраган, дим. Юлламa бирүчеләргә дә рәхмәт. Бәхетле тормышка булган икән ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА:

«ЙОРТЫБЫЗНЫҢ ТҮБӘСЕ ЮК»

Ил-көндәге вазгыять каләм ияләренә дә тәэсир итмичә калмый, билгеле. Язучылар Туган тел бәйрәмен нинди кәеф, уйлар белән уздыра? Халыкның телдән, китаптан ерагаюын ничек кабул итә, сәбәпләрен нәрсәдә күрә? Болар һәм башка борчыган мәсьәләләр хакында Татарстанның халык язучысы Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА белән сөйләштек.

:: Апрель – Тукай ае, дибез. Аның образы халыктан ерагаймадымы, Нәбирә апа?

– Шәхсән мин үзем, Тукайдан ераклаштык, дип әйтмәс идем. Мәсәлән, Тукайның туган көне кысасында без, бер төркем язучылар, Балтач авылларында мәктәп укучылары белән очраштык, Тукайның әнисе Бибимәмдүдә абыстайның каберен зиярәт кылдык. Бу чарада да, Балтачта үткән шигърият бәйрәмендә дә халык күп иде. Орчык кадәрле малайның Тукай булып уйнавы, сабыйларның шагыйрьнең шигырьләрен яттан сөйләүләре сөендерде. Ә бит Туган тел бәйрәме бездә генә түгел, бөтен төрки дөньяда бәйрәм ителә. Финляндия татарлары да, Төркиядә, Америкада, Польшада һәм башка илләрдә яшәүче милләттәшләр дә бу көнне көтеп ала. Минем үземә яз Тукай туган көннән башлана. Бу бөтен бәйрәмнәрдән дә якынрак. Без бит Тукайны искә алып, аның туган көнен зур бәйрәм чарасына әверелдереп, үзебезне – татарларны да зурлыйбыз. Әлеге күркәм традиция, Алла боерса, киләчәктә дә дәвам итәр дигән өмет белән яшим мин. Тукайга без тагын да якынаербыз әле.

:: Чирен яшергән үлгән, диләр бит. Без – китаплы халык, дип үзебезне алдамыйбызмы икән?

– Бәлки, алдыйбыздыр. Яшерен-батырын түгел, китап укучылар саны кимеде. Мин аны каләмдәшләремә дә әйтәм. Кайберләре: «Беттек, дип сөйләшмә, оптимист булырга кирәк», – диләр. Мин бит: «Беттек!» – димим. «Проблема бар», – дим. Кайчакта дөньяга күзеңне ачып карарга кирәк. Халыкның китаптан ерагаю сәбәпләренең берсе яшәешебезгә интернет үтеп керүе, диләр. Юк, җәмәгать, адәм баласының күңел кыры тарайды, китапны ул изге төшенчәләр рәтенә куймый башлады. Без – сүз кодрәтен тоеп, китапны олылаган буын. Бүген исә кеше алай уйламый. Юкса тормыш та безнең чор белән чагыштырганда яхшырак. Без үскәндә суыткыч урынына кар базы иде. Хәзер һәр өйдә хәтта берничә суыткыч тора, газы, суы кергән, инде печән, утын әзерлисе дә юк, мәшәкать әзрәк. «Фәлән-Фәләннең әсәре басылды, укы әле», – дисәң: «Әй, вакытым юк», – ди ул. Нишләп җитми соң вакыт, ә? «Ахырзаман якынлашканда вакыт чутын югалтырлар», – дип әйтә иде безнең мәрхүмә әби. Аннан соң халыкны битарафлык басты. Татар үз-үзен милләт буларак саклармы, ана телебез тагын да аянычрак хәлләргә төшмәсме? Бу сораулар журналистларның һәм язучыларның гына хәсрәте булып калды. Хәтта сәхнә җырчыларында да андый борчылу юк.

Шаккатып күзәтәм һәм үземнең чор белән чагыштырам да бу сорауга җавап таба алмыйм. Нишләп алай соң ул, кияр кием күп, ашарга нинди генә ризык юк бит?! Без үскәндә төп ризык бәрәңге иде, хәзер инде бәрәңге бакчалары да утыртылмый, күбесе анда чүп үлән үстерә. Төгәл генә җавап биреп һәм җавабы белән халыкны битарафлыктан арындырып, гамь өстәсәң иде.

:: Шундый уйлар белән алганда, нишләп язучы булдым икән, дип үкенмисезме?

– Үкенмим. Күрәсең, язмышыма шулай язылгандыр. Хәзер инде китәм дисәң дә, китеп булмый, «тиеш» дигән богау белән богауланган чөнки. Каләм кайвакыт бәргәләп, суккалап та эшләтә, кайчак сөендерә, кайчак көендерә дә. Гел иҗат белән генә яшәлмәде, балалар да үстердек, хәзер оныклар белән әвәрә киләбез. Әйе, тормыш итүләре авыраеп киткән минутларда шундый уй башка кергән иде. Туктарга, дидем, җитте, дидем. Син беләсеңме, Гөлинә, язу эше ул җир казуга тиң. Шөкер, китаплар басылды, укылмадык түгел, укылдык, Аллага шөкер. Әсәрләр сәхнәләрдә дә куелды, иҗат бәяләнде. Тукай премиясе дигән иң дәрәҗәле премияне дә алдык, халык язучысы да булдык. Инде туктаргадыр дигәндә, икенче уй башымны бутый шул. Ничек инде син туктыйсың, янәсе? Әле бит сиңа язасы да язасы. Мин, укучыларым тезелеп тора, дип мактанмыйм. Мин кем өчендер язмыйм. Каләмне ташласам, үземне ятим калган төсле тоярмын кебек. Кәеф кырылганда, хәлеңне беркемгә дә аңлата, беркем белән бүлешә алмаганда, ак кәгазь иң якын дустыңа әйләнә. Аңа түгеләсең дә, җиңел булып китә. Менә әле генә «Ике рәссам» дигән бәян тәмамладым, инде икенчесе чиратка баскан. Шулай кайвакыт, тәнәфес ясап, ял итәргә дә өлгермисең.

:: Язучы булуыгызны кайчан аңладыгыз?

– Язучы булуымны әле бүгенгә кадәр аңламыйм. Хәтта, мин – язучы, дип чыгып әйтергә дә оялам. Андый нәрсә юк миндә. Мәкаләләр язганда да, язучы, дип бервакытта да куймадым. Халык язучы дисә, шуңа канәгать. Мактану дип әйтмә, бәлки, халык исемнән язучы икәнемне беләдер.

:: Беренче китап чыккандагы тәэсирләр беренче мәхәббәт кебек, диләр, шулаймы?

– Беренче китабым – «Су хикәяте» бик озак басылмады, Татарстан китап нәшриятында 3 еллап ятты. Ул нәшриятка тәкъдим ителгәндә миңа 18 яшьләр тирәсе булгандыр. Ул чакларда без шагыйрә Саҗидә апа Сөләйманова белән хат языша идек. Ул минем әсәрләрне укый, шуңа китап турында да гел сорашып торды. Юк бит әле, дигән җавапны алгач, бик ачуланып, Шәүкәт Галиевкә хат язган икән. Шәүкәт абый – ул вакытта Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире. Шуннан соң боз кузгалды, 1981 елда минем беренче китабым чыкты. Бу – минем КДУның журналистика бүлеген тәмамлаган елым. Ул елларда районнарда эшләү мәҗбүри иде, ә инде минем китап чыккач, үзем теләгән җирдә калу мөмкинлеге бирелде. Шулай итеп Казанда калдым. Әйе, беренче китап ул – зур сөенеч. Китапны нәшриятка тапшырган саен көтәсең, дулкынланасың инде. Син шуның белән яшисең, шуңа күпме көч саласың бит.

:: Сез интернет белән «дус»мы?

– Мин бөтен яңалык белән танышып барам, әмма социаль челтәрләргә махсус кермим. Минем керәсем, баткаклыкка батасым килми. «ВК»да үз битемне алып бардым, ләкин аны да ташладым. Мин аны кирәксенмим. Беренчедән, язу өчен бик күп вакыт кирәк, аннан тыш без очрашуларга да күп йөрибез. Аларга киткән вакытны кызганмыйсың да, исәпләмисең дә, ә социаль челтәрләр өчен вакыт кызганыч икән.

:: Европада, Россия әдәбиятында да китап блогерлары бар, безгә кирәкме ул? Аның файдасы булырмы?

– Яшьләр өчен кирәк. Алар интернетка әсәрләрен куя, күпме кеше караганын, аларның реакцияләрен карап бара. Мин аны кирәксенмәдем, моңарчы китапларым яхшы сатылды. Киләчәктә ничек булыр – анысын әйтә алмыйм инде.

:: Китапны сату сезнең үзегездән торамы? Чөнки сезнең китаплар интернет сату мәйданнарында, шул ул «Авито»да, «Лабиринт»та һәм башкаларда да бар. Укучыга таратуның бу юлы ни дәрәҗәдә отышлы?

– Китап сату миннән тормый. Минем бөтен китап та Татарстан китап нәшриятында чыкты, таратуны да алар кайгырта. Күп өлеше китапханәләргә китә дип беләм. Ә инде татар китабы интернетка да чыккан икән – бу бик яхшы. Кызыксынган кеше, кайда яшәвенә карамастан, китапны заказ белән кайтарта ала дигән сүз бу. Әйтик, бүген минем китабымны Башкортстанда һәм Самарада яшәүчеләр сорый. Кайвакыт аларга китапны бүләк итеп почта аша җибәрәм. «Интернеттан карагыз», – дип әйтергә булыр әле.

:: Китап дигәннән. Татарстан китап нәшрияты кайсы авторның китабын чыгаруны үзе хәл итә. Теләсә кайсы автор, китабын биш елдан соң түгел, бүген чыгарасы килә. Бу очракта мәсьәләне ничек хәл итәргә?

– Татарстан китап нәшрияты – бүген бердәнбер таләпчән нәшрият. Аның мөхәррирләре һәр кулъязманы энә күзеннән үткәрә. Анда фәлән кешене бастырмыйлар, дип, минем бер дә гаеплисем килми. Чөнки нәшриятның үз комиссиясе бар, аның составына берлек рәисе дә кергән. Матур әдәбияттан тыш социаль әһәмиятле, фәнни, тарихи һәм балалар өчен китапларны да чыгарырга кирәк. Барысын да исәпкә алганда, нәшрият елына хәйран гына китап чыгара. Язучыларның китаплары чыгып бара, зарланырга сәбәп юк дип уйлыйм. Бүген мине иң борчыганы – әрсезлек. Бу берлеккә кабул ителгән агъзаларга да, китапларга да кагыла. Әгәр әлеге мәсьәләләргә таләпчәнрәк булмасак, халык, безнең әдәбият шушы икән, дип күңелсез нәтиҗә ясаячак һәм бик аз санлы калган китап сөючеләр дә әдәбияттан биздәчәк.

:: Язучылар берлеге үзенең нәшриятын булдырса?

– Ркаил Зәйдулла берлеккә сайлангач, күп кенә идеяләре белән бүлеште. Аның тырышлыгы белән тәрҗемә бүлеге яхшы гына эшләп китте. Әйтик, Төркиядә бер төркем прозаикларның әсәрләре чыкты. Азәрбайҗанда татар әдәбияты үрнәкләре басылды. Роза Туфитуллованың «Язмыш җиле» әсәре русча, төрекчә һәм француз телләренә тәрҗемә ителде. Бу эшләрне тәрҗемә бүлеге пропагандасы нәтиҗәсе дип саныйм. Ә инде нәшрият мәсьәләсенә килгәндә, безгә тагын бер нәшрият кирәкме икән? Бүген Татарстан китап нәшрияты гөрләп эшләп тора. Аңа көндәш кирәкми. Бу – минем фикер. Бәлки башка фикердә булучылар да бардыр. Ә Язучылар берлегенең нәшрияттан башка да эшләре күп. Кибет ачылса, пропаганда бүлеге оешса, яхшырак булыр иде.

:: Әдәбиятта цензура бармы?

– Сюжет, тел, милли мәсьәләләргә кагылганда, миндә һәрвакыт эчке цензура «эшли». Гомумән алганда, бүген цензура була алмый. Чөнки шәхси нәшриятлар бихисап, алар нәрсә алып киләсең – шуны бастырып бирә. Сәнгатьтә, бигрәк тә җыр сәнгатендә дә цензура юк.

:: Һәр кеше үзенең талантын балаларында да күрергә тели. Сезнең кызларыгызда язу таланты бармы?

– Мин әдәбиятка бик матур вакытта килдем. Халык кырылып китап укый, очрашулар булып тора, өчәр сәгать чыгыш ясыйбыз, халык – бездән, без халыктан аерыла алмыйбыз. Шуннан канатланып язасың, язганыңны бастырырга – чират, анда үтәргә тырышасың. Әдәбияттан тыш журналист булып та эшләгәнгә,

эшем үзем белән дә кайта. Әле ул вакытта балалар да кечкенә. Бервакыт кечкенә кызым: «Әни, синең бу кәгазьләреңне яндырыр идем», – димәсенме. Күрәсең, аларга игътибар җитмәгәндер инде. Балаларга бит, син болай ит, бу юнәлештән кит, дип әмер биреп булмый. Олы кызым үзен белә-белгәннән бирле табиб булам дип әйтә иде. Уенчык итеп, гел Айболит тартмасын сайлады. Дөрес, кечкенәсе, кәгазьләреңне яндырам дигәне, журналистикага барам, диде. Анысына үзем, бармыйсың, дидем. Гәрчә язмалары «Идел» журналында басылса да. Минем ничек эшләгәнне, гаиләгә дә вакыт калмаганны күрдең бит, дидем. Тыңлады. Юрист һөнәрен сайлады, эшен бик ярата. Ике кызым да минем хезмәтемне аңлый һәм хөрмәт итә.

:: Язучының матди хәле канәгатьләнерлекме?

– Без әдәбият мәйданына аяк баскан заманнарда Нурихан абый Фәттахның, китап гонорарына өч ел яшәп була, дип әйткән сүзе истә. Хәзер юк инде андый нәрсә! Грант һәм конкурслар белән генә дә хәл итеп булмый бу мәсьәләне, чөнки анда урын чикләнгән. Язучылар 5–6 ел элек бу мәсьәләне күтәреп карады, инде хәл итеп булмаслыгын аңлагач, үзләренең хәлләре белән килештеләр, күрәсең.

:: Бүген иң зур проблема нәрсә?

– Милләт йорты төзергә маташабыз, очрашулар да, бәйрәмнәр дә, конкурслар да уза. Әмма йортыбызның идәне белән түшәме җәелмәгән. Нәрсә соң ул дисәгез, ул – татар теле. Аны ихтыярига калдырдылар. Баласын татарча укытырга риза булган ата-ана бик сирәк. Хәзер инде татар гимназиясе дип барган җирдә дә синең бер сүзеңне дә аңламаган балалар шактый. Бу проблема үзенең бәйсез милли мәгарифең булганда гына хәл ителә ала. Әгәр өч баскыч үтмәсәк, бу баскычның беренчесе – балалар бакчасы, икенчесе – мәктәп, өченчесе милли университет – киләчәктә төп башына утырабыз. Соңгысын мин татар телен нигез итеп алган хәлдә, инглиз, кытай һәм башка телләрне үзләштерергә мөмкинлек биргән уку йорты дип күз алдына китерәм.

:: Бер әңгәмәдә без сезнең белән, әдәбиятта хатын-кызга караш икенче, дип сөйләшкән идек. Хәзер инде кайсы өлкәдә дә алгы сафларда – хатын-кыз. Димәк, караш та үзгәргәндер.

– Хәзер андый караш сизмим. Яшьләр бер-берсе белән санлаша, бер-берсенә ярдәмләшә. Безнең заманда хатын-кызлы арткарак кую бар иде. Туфан абый Миңнуллин: «Хатын-кызга торып урын бирергә әдәбият – трамвай түгел ул», – дип тә әйткән иде. Көлеп, билгеле. Шундый шагыйрәләр бар: тел һәм милли мәсьәләләр турында язганда, моны хатын-кыз язган, дип әйтеп тә булмый хәтта.

:: Нәбирә Гыйматдинова мәхәббәт турында яза дисәк, килешәсезме?

– Яза-яза, яши-яши тема үзгәрә. Беренче әсәрләрдә күбрәк борынгы халык дәвалау ысуллары, гореф-гадәтләр бирелсә, хәзер инде милли проблемалар борчый. Аксубайда дин белән мәҗүсилек бер ызанда очраша. Чишмәләргә табыну, су ияләре, урман ияләре, абзар ияләре әле дә бездә сакланган. «Сәвилә» әнә шул тәэсирдә язылган иде. Мәхәббәт темасыннан бөтенләй читләштем, димәс идем. Бүген, шушы катлаулы заманда, милләт сыкранганда, гамьсез кеше кебек бернәрсә күрмичә, хисләнеп йөрү уңайсызрак шул...

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

И кешем! Бу дөньяга аваз салган беренче минутларыңнан ук Язмыш сине үзенең кочагына бөтереп алып кереп китә дә, теләгәнчә елатып, теләгәнчә җырлатып, теләгәнчә кыйнап яшәтә дә яшәтә. Әгәр дә син аның теләгәненә каршы киләсең икән, ул тагын да сынауларын өстәп бирә. Ул язган юлдан гына барам дисәң дә, сукмакларың чуалмас димә: адашыр өчен әллә ни күп кирәкми. Кайберәүләр, Язмышка бирешергә теләмичә, гомер буе көрәшәләр, үз дигәннәрен үз итеп, алга баралар. Ә бит ихтыяр көче дигәне дә бөтен кешедә дә бертөрле түгел. Дәвыллар бөгеп салганда яңадан күтәрелеп китүчеләр белән беррәттән, әкрен генә искән җилгә дә түзә алмый егылып калучылар да аз түгел.

не!» – дип җавап кайтарды. Камилнең бу сүзләре фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килде дә, килмәде дә...

***

Әтисенә ялга кайтырга ышандырып калган Камил сүзеннән чыкмады. Район үзәгендәге автовокзалдан каршы алырга бу юлы әтисе үзе килгән иде. Әтисе юл буена уен сүзләр сөйләп кайтса да, ярты сәгатьлек юлны бу юлы озаграк узган төсле тоелды Камилгә.

Теге көнне башлаган «килен» темасына кагылмагач, Камил сөенеп куйды. Тик сөенүе иртәрәк булган икән. Тамак ялгап алып, сеңелләре белән сөйләшеп утыргач, әтисе белән әнисе аны кече якка чакырып алдылар. «Улым, тау белән тау очрашмаса да, кеше белән кеше очраша икән», – дип сүзен башлады әтисе.

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА

СИН КЕМ КЫЗЫ?

***

– Камил, син мине яратасыңмы?

Егерме елдан артык торган хатынының авызыннан чыккан соравыннан соң Камил, телевизор пультын бер каналдан икенчесенә күчерә башлады.

– Әнисе, яратмасам, бергә яшәмәс идек.

– Ышан сиңа!

Фәнәзия кәнәфидән Камил янына диванга күчеп утырды.

– Камил, шулай да әйт әле, яратасыңмы, юкмы?

Камил, хатынының өзми куймый торган гадәтен белгәнгә, җиңелчә генә иңеннән кочаклап алды: «Яратам, яратам, әнисе!»

Әле ярый Фәнәзиянең телефоны чылтырап, икенче бүлмәгә чыгып китте. Юкса: «Яратам, яратам, әнисе!» – дигәч, комач кебек кызарып утыру халәтеннән чыга алмаганын сизмичә калмас иде.

Көннең дә туры килүен дип әйт әле син аның! Нәкъ менә бүген ул җитәкләгән оешмага, яшь чагында яратышып, мәңге аерылмаска сүз биргән Яугьһәриянең кызы эшкә килгән көнне! Дөрес, хатыны бу хакта белми. Шуңа күрә, хатынының соравы туры килү генә иканенә Камил һич шикләнми. Шулай да сак булырга кирәк!

Өйләнешүләре дә кызык булды аларның. Гадәттә, колхоз җитәкчеләре кыш көне ял итәләр. Бер елны Камилнең әтисе, Яңа ел бәйрәмнәре үткәч, Кырымга санаторийга китте. Кайтышлый, улы янына сугылды. Ирләрчә, сүзне уратып тормый, турыга әйтте:

– «Килен» таптым әле мин! Диплом алу белән башлы-күзле итәргә булдык сине.

– Кызык икән! Ә мин ризамы соң?

– Риза булмый, кая барасың, улым?

Камил әтисенә Яугьһәрия турында сөйләмәкче булып авызын ачкан иде, әтисе өлгеррәк булып чыкты:

– Ярый, ялга кайткач, сөйләшеп бетербез. Кыз бер кашык су белән йотарлык, соңыннан үзең дә рәхмәт әйтерсең, – дип, сөйләшүгә нокта куйды.

Ул кичне Яугьһәрия Камилнең кәефенең үзгәргәнен әллә каян сизеп каршы алды.

– Әллә бер-бер хәл булганмы, төсең качкан Камил!

– Юк, бар да тәртип, кошчыгым. Диплом эше беразарыткандыр. Әйдә, киен, тышта шундый саф һава, йөреп керик әле.

Педагогия институты тулай торагының вахтерлары барысы да Камилне таныйлар, документ та сорап тормыйлар. Чыгып киткәндә: «Кире кайтарырга онытма», – дип озатып калалар. Бүген дә дежурда утыручы Соня түти нәкъ шулай диде.

Тик Камил Соня түтине аптыратып: «Кайтармыйм, бүген урлыйм Яугьһәрияне!» – дип җавап кайтарды.

Камил әнисенә күз төшереп алды. Әнисенең әтисе сөйләгәнен куәтләп торуы йөзенә чыккан иде. «Санаторийда институтта бергә укыган иптәшемне очраттым. Күрше өлкәдә райком секретаре булып эшли. Бик акыллы, тырыш, максатчан иде студент елларында ук. Сөйләшеп киткәч, синең белән бер яшьтә кызлары барлыгы ачыкланды. Быел үзләрендә институт бетерә. Фотосын да күрсәтте, бик чибәр. Исеме – Фәнәзия. Ике атна буе гел бергә йөрдек диярлек курсташ белән. Кыскасы, без сез яшьләрне таныштырып, кавыштырырга булдык». «Камил, әтиең кеше таный ул, – дип сүзгә кушылды әнисе, – үзеңнең дә өйләнердәй кызың күренми бугай».

Камил ничек итеп әтисе белән әнисенең күңелен кайтармый гына Яугьһәрия турында әйтергә кирәклеген уйлап бетермәгән иде әле. «Иртә кичтән хәерлерәк, диләрме әле? Иртәгә сөйләшеп бетерсәк, ничек булыр?» Әтисе ризалыгын белдереп ияген какты.

Ярты төнгә кадәр йоклый алмый ятты Камил. Кичә Яугьһәриягә әтисенең ял йортыннан «килен» табып кайтканын көлеп сөйләсә дә, монда эшләр еларлык булып бара икән ләбаса. Әнисе белән әтисе чынлап торып туйга әзерләнеп яталар.

Камил сөйгәнен бер күрмәгән-белмәгән кызга алыштырырга җыенмый иде. Тик... Әтисенең холкын белә Камил. Аныңча булмаса, яхшылык көтмә. Әнисе дә гел: «Әтиегез ни әйтер, әтиегез риза булмас, әтиегез белсә, ачуланыр», – дип үстерде аларны. Камил өч ел флотта хезмәт итеп, институтның соңгы курсында укып йөргән егет булса да, әти һаман әти булып кала... Үзен дә тиргәп алды Камил. Нигә элегрәк сөйләнмәде соң әле ул Яугьһәрия турында әниләренә? Сорау биреп торган була бит әле! Әтисенең хупламавын белеп яшерде ул. Камил институтта укый башлагач, әтисенең тел төбендәге «үзеңә тиң... безгә тиң... нәсел-нәсәбе... кода булырдай» сүзләре ниндирәк кызларны сайларга кирәклегенә ым биреп тора иде. Ә Яугьһәрия – нибары гади колхозчы кызы. Үзе дә авыл малае булгангамы, Камил, шәһәр егетләре күбрәк сайлаган техник институтта укыса да, авыл кызларын якын итә шул. Факультетның партия оешмасын җитәкләгән «авыл малае»на шәһәр кызлары да «бәйләнеп» карадылар, тик җиңә алмадылар. Яугьһәрия белән очраша башлагач, әкренләп югалып беттеләр аннан үзләре.

Яугьһәрия белән алар югары уку йортлары студентлары арасында барган чаңгычылар ярышында таныштылар. Зәңгәр күзле, алтын сары чәчле кызның кино актрисаларыннан бер кем җире дә юк иде. Бәлки, артыграк та булгандыр әле. Ярышлар вакытында аның янында берничә егетнең бөтерелеп йөргәнен дә искә алып куйды шул вакытта Камил. Кыз Камилгә үзе килеп эндәшмәсә, алар ул көнне танышып та китмәгән булырлар иде. Үткерлеге бар шул, ни әйтсәң дә, Яугьһәриянең. Сизгерлеге дә бар. Уңганлыгы да бар. Тик бер килмәгән ягы бар икән – «начальство» баласы түгел. Камил үзенең юморыннан үзе көлеп куйды.

– Улым, әллә бүген төшкә кадәр йокламакчы буласың инде?

Камил әнисенең тавышына уянып китеп, сәгатькә күз салды. Тугыз тулып килә. Әйе, авыл өчен бу чынлап та «төшлек». Әтисе хуҗалыкны әйләнеп кайтыр вакыт җиткән.

– Әни, ун минуттан синең карамакта булам.

Камил сикереп торып, мускулларын яза башлады. Әтисе озак көттермәде. Җыелышып ризыкланып алгач, урта ишекне ябып куйдылар. Берсе җиденче, икенчесе тугызынчы класста укучы сеңелкәшләре колагына иртәрәк иде әле бу сөйләшү. «Менә сиңа иске авыздан яңа сүз. Моңа кадәр берниндидә Яугьһәрияләр юк иде бит әле», – дип, Камилнең сүзен бүлде әтисе.

Яугьһәриянең кайсы яктан, әти-әниләренең кем булуын ачыклагач, йөзенә ризасызлык билгеләре чыккан әтисе:

– Арагыз тирәнгә кермәгәндер бит? – дип турыга сорады әтисе.

– Кермәде.

– Соң... Тирәнгә кермәгәч.

– Тирәнгә түгел, бик тирәнгә керде, әти. Мин аңа өйләнергә сүз бирдем.

– Бары шул гынамы?

Әтисе өйне яңгыратып көлеп җибәрде.

– Сүзгә син хуҗа, ничек биргәнсең, шулай аласың. Калага баргач, озакка сузмый, арагызны өзү җаен кур. Җәйгә Фәнәзия белән туегыз, менә шул.

Аннан Камил белән сүзне бетергәнен аңлатып, хатынына дәште:

– Кырым күчтәнәчләрен әзерлә әле, Камилне озаткач, Диларисларга сугылырбыз.

***

Камил, шоферына чылтыратып, үзен килеп алмаска кушты. Шәхси машинасында башта хатынын илтеп куйды, аннан эшенә китте. Эш башланырга бер сәгатьләп вакыт бар, хезмәткәрләр әле берсе дә күренми. Камил кичәге хатны тагын бер тапкыр укып алырга булды. «Камил Касыймович! Исәнмесез! Әгәр мөмкин булса, Сезгә шушы хатны тапшырган кызны – Камилә Ризвановага эшкә урнаштырырга ярдәм итә алмассыз микән. Хәзер югары уку йортын бетергәннәрне, эш тәҗрибәсе булмау сәбәпле, эшкә алырга тырышмыйлар. Камилә йөзгә кызыллык китерә торган бала түгел. Сезгә ышанып, әнисе Яугьһәрия». Бер белмәгән чит кешегә язган кебек «сезләп» сырлаган хатын Яугьһәрия. Хәер, чит кешеләргә әйләндерде шул язмыш аларны.

Камилә тәмам әнисенә охшаган. Кичә кабинетына килеп кергәч: «Яугьһәрия!» – дип, чак кына ычкындырмый калды бит Камил. Ул хатка карап уйга калды. Ничә еллар узгач, Яугьһәрия кабат аның язмышына ни өчен килеп кермәкче була соң әле? Җитмәсә кызы аша? Яугьһәрияне бик яхшы белә Камил: тиктән генә мөгез чыгара торган кеше түгел ул. Камилнең әтиләре аңа өйләнергә рөхсәт бирмәгәч тә, шашынып, тилереп дәгъвалашып тормады. Диплом алу белән, күрше республикадагы районнарның берсенә химия-биология укытучысы булып китте дә барды. Камил аның бу адымын очраклы рәвештә булса да күрешеп яшәмәс өчен иканен белә иде. Әйе, алар башкача очрашмадылар. Хатыны Фәнәзиянең Камил өчен җан атып яшәве дә, бәлки, сәбәп булгандыр. Бәлки...

Дәвамы бар >

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

медицина тикшеренүе узу өчен СЕРТИФИКАТ уйната

1 **ЯЗЫЛ!** 2023 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына язып

П2435 – җомга саны **512 сум 70 тиен**

П2409 – атнага дүрт тапкыр чыга **1227 сум 30 тиен**

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040 info@vatantat.ru

420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘК ОТ!**

Сертификатлар:
1) 9 төрле УЗИ+уролог консультациясе;
2) 9 төрле УЗИ+гинеколог консультациясе;
3) остеопат ярдәме.

Тулырак сайтта: vatantat.ru

Акция 2023 елның 28 апреленнән башлап 30 июнена кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

МЦ «НУРМЕД»

(843) 246-76-00
(843) 209-19-29

Күп төрле УЗИ тикшерүләре
Анализлар
Тәҗрибәле табиблар

*АКЦИЯ. Тулы тикшеренү үтү – бары тик **15 750 сум**

*Акция 2023 елның 1 гыйнварыннан 30 маена кадәр дәвам итә.

Тулырак сайтта: nhkrt.ru

Реклама 18+

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШҮ СОРАЛА.

Сканворд

Т.Галиуллин романы; Очкыч; Х.Насретдин «аты»; «... кигә автомобиль»; Краннан ага; Иртән ашыйлар; «Гомер ... димә»; «Адымнар» тапшыруы сәхифәсе; Белән; Нота; Казанда татар балалар бакчасы; Тирәү; «Өстәлдә ялгыз ..., чәем суынып беткән»; Ишек йозагы элгече; Киа ...; Җәп түгел; Тилемсә; Кулмак өлеше; Тека яр; Ринат Мөхәммәдиев китапе; Элеккере сәлам; ... Чаплин; Калкавылы таяк; Сабантуйда тарталар; Ерак түгел; Идән югыч; Нота; Чит; ...-маз; Заводта эш урыны; Атос һәм Портос дусты; Ике Рамил; «... атым, ак канатым»; Кояшны алыштыра; Аны чайкыйлар; Сөйгән ...; ...-Батыр; Ишарә; Ифтар ...; Каралты-кура җирлек; Хоккей командасы; Тарихи кыйммәтле машина; ...-тирә; Бодай түгел; Темперамент; ..., син, ул, алар; Борын сизә; Композитор ... Сәйфуллин; Ата-...; «Гомерләр үтә ... ул»; Татарстан районы

КАТНАШ АЗЫК, АШЛЫК

ФИНИШ БРОЙЛЕРЫ өчен (26 көнлек һәм аннан зуррак бройлерлар өчен)

КАТНАШ АЗЫК

Глазов һәм Богдановичь шәһәрләре заводларында җитештерелгән терлек азыгын (бройлерлар, йомырка салучы тавыклар, бытбылдыклар, йорт куяннары, мөгезле эре терлек, куркалар өчен), шулай ук аертылмаган солт калыштыручы ризык, мөгезле эре терлек өчен тоз һ.б. сайлап алу мөмкинлеге зур.

Казан, Техническая урамы, 15. **тел.: +792-704-99-706**

Чаллы, Магистральная урамы, 1а/1. **тел.: +792-767-27-366**

сыер рәсеме төшерелгән сары баннерны эзләгез!

Безнең сайт: agroline1.ru

реклама

Әз-мәз мәзәк

– Тышкы һәм эчке халәтең гармониядә булырга тиеш. Миннән үрнәк ал. Мин тыштан дә әллә ни түгел, эчтән дә.

* * *

– Криптовалюта һәм блокчейн турында видеоролик карадым һәм шуны аңладым: мин дөрес юлда түгел икән – миңа эшләргә кирәк, ә мин видеоролик карыйм.

* * *

Яфрак-яшелчә ашап, саф һавада йөреп ябыгырга тырышучы кешеләр, әйтегез әле, ник бегемот ябыкмый?

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Тәүбә, ишәк, су, ре, Бәләкәч, Рио, Динә, так, кармак, яка, якын, чүпрәк, ят, аз, адаш, станок, ай, кер, яр, ихата, ым, ашы, Эльмира, ис, ана, икән, Ганс.

Вертикаль: Сират, Чарли, Ту, Акбүз, холык, ботка, СКА, үтә, раритет, мин, Арамис, Әнә, аркан, Кадак, до, ара, илә, ясак, кыя, арыш, келә, сантый, Мырау.

Сәхифәне Данил САФАРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 260

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – **газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Вақлап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.)**.

16+